
# ШУРА

№ 44
2024



2007114582956

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Коръәни Кәримне уку әдәпләре . . . . . . . . . . . . . . . 14
Ислам динендә тырыш булуның әһәмияте . . . . . . . . . 19
Телләр – Раббыбызның нигъмәте . . . . . . . . . . . . . . 24
Аллаһы Тәгаләнең «Әл-Фәттах» исеме . . . . . . . . . . . 30
Җомга көне әдәпләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Ислам финанслары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Расүлгә итагать – Аллаһыны ярату . . . . . . . . . . . . . 46
Гаиләдә дини һәм милли тәрбия . . . . . . . . . . . . . . . 53
Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . 60
Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең саубуллашу хотбәсе һәм соңгы нәсыйхәте . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Корбан гаете хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Корбан гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Гөнаһларыңа аклану эзләмә . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Сүзеңдә тору – иманнан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Мөхәррам ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Декабрь-Февраль . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

**«ШУРА» дини альманах, № 44** **12+**

апрель–июнь 2024
шәүвәл–зөлхиҗҗә 1445

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Рәмзилә Маннанова

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ильяс Гарифуллин

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Тышлыкның 1нче битендә Кәгъбәтуллаһ сурәтләнгән, соңгы битендә гарәпчә «Корбан мөбарәк» дип язылган.
Рәсемнең авторы: Zurijeta // shutterstock.com/ru/image-photo/kaaba-mecca-sky-background-1334807957
Mohammet Amin //https://www.shutterstock.com/ru/image-vector/adha-mubarak-arabic-calligraphy-greeting-card-2322149597

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Жуковка урамы, 2нче йорт.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 22.03.2024
Чыгу көне: 8.04.2024


*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*


*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*


*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*


**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ❁ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ❁ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ❁ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ❁ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ❁ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ❁ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ❁ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ❁ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ❁ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ❁ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ❁ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ!❁ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ❁ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ❁

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________ ❁

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________________ ❁

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ وَاللّٰهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәә-нә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалəллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге до-ганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфирииинә вәл мүкыыймииинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ____________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгеләүен.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*12 нче апрель вәгазе,*
*шәүвәл аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Коръәни Кәримне уку әдәпләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрне юктан бар итеп, тәрбия кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңелләребез түреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифләребез ирешсә иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ил-көннәребезгә – иминлек, тынычлык, авыру-сырхауларга – хәерле шифалар, имансызлыкта, тәүфыйксызлыкта йөргән бәндәләргә туры юлны табарга ярдәм итсә иде, аларны иманга китереп, тәүфыйк-һидаять, истикамәтләр насыйп әйләсә иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Изге җомга көнебез һәркайсыбызга мөбарәк булсын. Аллаһы Тәгалә ике җомга арасында вафат булган дин кардәшләребезнең гөнаһларын ярлыкап, рухларын шатландырса иде. Аллаһы Раббыбыз изге җомга көнендә кылган догаларыбызны, игелекле гамәлләребезне кабул итеп, безне Үзенең чиксез рәхмәтенә ирештерсә иде.

Изге Рамазан аенда бик күп дин кардәшләребез Коръән укыды, күпләр аны хәтем кылды. Инде бу күркәм гадәтне Рамазанда гына түгел, ел дәвамында да ташламасак иде.

Хакыйкатьтә, кешеләр арасында Коръәнне гәҗит сыман укучылар вә аның мөкаддәслеген аңлап бетермәүчеләр бар! Коръәни Кәрим Аллаһының мөкаддәс вә мөбарәк сүзләре булу сәбәпле, аны кадерләп тоту һәм хөрмәт

итү тиешле. Мөселманнар өчен аннан да кадерлерәк китап юк, шуның өчен дә алар Коръәни Кәримгә генә хас булган әдәпләрне сакларга тырышалар. Бу әдәпләр ике төргә: тышкы һәм эчке (кальби) әдәпләргә бүленәләр.

Коръәни Кәримне укыганда тышкы әдәпләр:

1. Коръәни Кәримне укучының тәне госел-тәһарәтле, киеме гаурәтен каплаган һәм чиста булырга тиеш.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالسَّابِقُونَ السَّابِقُونَ

**«Пакьләнгәннәр генә аңа кагыла ала».**

«Әл-Вакыйга», 56:10

2. Тешләрне һәм авызны мисвәк белән пакьләү. Сүз һәм аваз чыга торган урын булганга, без аны Аллаһы ризалыгы өчен чистартабыз, шул рәвешле Коръәни Кәримне олуглыйбыз.

3. Коръәни Кәримне мөмкин кадәр кыйблага юнәлеп уку.

4. Төрле шөгыльләр, эшләр комачау итәргә тиеш түгел.

5. Коръәни Кәримне уку алдыннан «Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим», дип башлау. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَإِذَا قَرَأْتَ الْقُرْآنَ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

**«**[Расүлем!] **Коръән укыган чагыңда ләгънәтле шәйтаннан Аллаһыга сыен».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:98

Ягъни «әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим» дип әйт.

6. «Әт-Тәүбә» сүрәсеннән кала һәр сүрә башында «Бисмилләһ»не әйтү кирәк.

7. Коръәни Кәримне тәҗвид кагыйдәләренә нигезләнеп, тыныч тавыш белән уку. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَوْ زِدْ عَلَيْهِ وَرَتِّلِ الْقُرْآنَ تَرْتِيلًا

**«Яки аңа өстә** [һәм өчтән икесен гыйбадәттә үткәр]**. Коръәнне тәртил белән** [әкрен-әкрен, ачык итеп] **укы».**

«Әл-Мүзәммил / Чорналган», 73:4

8. Коръәни Кәримне тәртибе белән уку, ягъни сүрәләрнең һәм аятьләрнең тәртибен саклап уку.

9. Укый башлаган сүрәне ахырына кадәр укып тәмамлау.

10. Коръәни Кәримгә хөрмәт йөзеннән, аның мосхафын яткан хәлдә укымау. Ә менә яттан белгән сүрә яки аятьләрне яткан көе укуның гаебе юк.

11. Кеше мөрәҗәгатьләренә бүленмәү. Сәлам бирсәләр, сәламне кайтарып, Коръәни Кәримне укуны дәвам итү.

12. Яттан укыганчы мосхафка карап уку, чөнки Коръән аятьләренә карау – гыйбадәт (Искәрмә: намазда мосхафка карап уку ярамый).

13. Коръәни Кәримне матур тавыш белән бизәп уку, ягъни Коръән Кәримне көйләп, музыка белән укымау. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Коръәни Кәримне гарәп телендә, әдәби һәм олуглык ияләренең телендә укыгыз. Дөреслектә, миннән соң шундый кавемнәр килер, алар насаралларга охшатып җырлап көйләрләр».

14. Сәҗдә аятьләре килсә, тиләвәт сәҗдәсе кылу.

15. Коръәни Кәримне укыганда еларга һәм хошугъ халәтендә булырга тырышу.

16. Коръәни Кәримне өйрәнү-укыту ниятеннән кала, каты тавыш белән укымыйча, пышылдап уку мөстәхәб.

Коръәни Кәримне укыганда эчке (кальби) әдәпләр:

1. Коръәни Кәримне бирелеп уку, мәгънәсенә төшенергә тырышу, фикерләп уку һәм гамәл кылырга тырышу. Раббыбыз Аллаһы Үзенең Изге Китабында болай дип әйтә:

كِتَابٌ أَنزَلْنَاهُ إِلَيْكَ مُبَارَكٌ لِّيَدَّبَّرُوا آيَاتِهِ وَلِيَتَذَكَّرَ أُولُو الْأَلْبَابِ

«[Коръәни Кәрим] **Мөбарәк бер Китап ки, аны сиңа алар аның аятьләре хакында уйласыннар һәм** [нәфесләренең бозык теләкләреннән арынган] **аек акылга ия булганнар үгетләнсен дип иңдердек».**

«Сад», 38:29

2. Коръәни Кәримне укыганда аның кеше сүзе түгел, Аллаһы Сүзе икәнлеген истә тотып уку.

3. Коръәни Кәримнең төп максатын белеп уку, ягъни бу Китап савапка ирешү һәм гыйбрәт өчен укыла.

4. «Мин инде Коръәни Кәримне шәп укыйм», — дип масаймау, тәкәбберләнмәү, бәлки, киресенчә, түбәнчелек белән укып, нәфесеңне тәрбияләү.

5. Коръәни Кәримне укыган кешене тыңлаганда яисә ишеткәндә, сөйләшмәү, игътибар белән тыңлап, калеб белән фикерләү. Коръәни Кәримдә Хак Тәгалә болай дип әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, — бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

6. Коръәннән булдыра алган хәтле ятлау һәм ятлаганын онытудан саклану, чөнки Коръәни Кәримне ятлау — сөннәт гамәл, ә ятлаганыңны онытмау — вәҗиб.

7. Коръәни Кәримне укыганнан соң дога кылу.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*19 нчы апрель вәгазе,*

*шәүвәл аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ислам динендә тырыш булуның әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактаулар һәм дә сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак илчесе, безгә туры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде!

Ялкаулыкның безнең тормышка тискәре йогынтысын аңлар өчен, дин өлкәсендә зур белем яки бай тормыш тәҗрибәсе кирәк түгел. Борынгы заманнардан ук кешеләр ялкаулыкны хурлыйлар, ялкау кешеләрне мыскыл итәләр. Бу темага мәкальләр һәм әйтемнәр төрле телләрдә табыла, һәм бу сыйфатны үзеңдә юкка чыгару темасы төрле халыклар әдәбиятына үтеп керә.

Ислам ялкаулыкны хупламый гына түгел, ул иманлы кешедә аның урыны да булырга тиеш түгеллеген өйрәтә. Ялкаулык – ике дөнья уңышына һәм бәхетенә ирешүнең иң зур киртәләренең берсе. Тырышып эшләргә, ялкаулык белән көрәшергә кирәклеген Коръәндә, Сөннәттә һәм галимнәр сүзләрендә дә таба алабыз.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый дога кыла торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ، وَالْعَجْزِ وَالْكَسَلِ، وَالْبُخْلِ وَالْجُبْنِ ، وَضَلَعِ الدَّيْنِ، وَغَلَبَةِ الرِّجَالِ

Әллаһуммә инни әгууҙу бикә минәл-һәмми вәл-хәзәни вәл-гаҗзи вәл-кәсәли вәл-бухли вәл-җүбни вә даләгид-дәйни вә галәбәтир-риҗәл.

«Йә Аллаһым, мин Сине борчылулардан, кайгылардан, зәгыйфьлектән, ялкаулыктан, куркаклыктан һәм саранлыктан, бурыч йөгеннән һәм кешеләрнең золымыннан саклавыңны сорыйм»[1].

Ялкаулык безгә нинди зыян китерә? Беренчедән, бу безнең гыйбадәтебездә җитди киртә булып тора һәм безне яхшылык эшләүдән тоткарлый. Ялкаулыкка бирелеп, аның җитәкчелегенә ияреп, без үзебезне әҗер-саваптан мәхрүм итәбез. Шул ук вакытта, без иманыбызның иң мөһим принципларының берсен онытабыз: кайгы-хәсрәтне мәңгелек дөньяда белмәс өчен, бу дөньяда тырышлык күрсәт.

Ялкау кеше, гадәттә, җавапсыз була. Ул үз вазифаларын санга сукмый, үзе янындагы кешеләрнең дә хокукларын саклауга битараф була. Гадәттә, ялкау кешеләр файдалы эш башкару урынына күп сөйләшәләр. Ә Коръән безне сүзләребезнең гамәлләр белән туры килмәвеннән кисәтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لِمَ تَقُولُونَ مَا لَا تَفْعَلُونَ ﴿٢﴾ كَبُرَ مَقْتًا عِندَ اللَّهِ أَن تَقُولُوا مَا لَا تَفْعَلُونَ

> **«Ий иман китерүчеләр! Ни өчен эшләмәячәк нәрсәләрегезне сөйлисез? Эшләмәячәк нәрсәләрне сөйләвегезгә Аллаһының ачуы** [һәм нәфрәте] **бик зур».**

«Әс-Сафф / Саф», 61:2–3

Ялкаулыкка бирелгән кеше үзенең кадерле вакытын югалта. Минутлар, сәгатьләр, көннәр, айлар һәм хәтта гомер еллары уза, ләкин ул орлык чәчми,

[1] Әл-Бохари җыентыгыннан.

урмый. Әлбәттә, ул вакытын ниндидер эшләр белән уздыра, ләкин бу, гадәттә, йә буш һәм файдасыз, йә шулкадәр аз файда китерә торган гамәлләр була, аларны башка, чыннан да мөһим, үзенә һәм якыннарына чын файда китерә торган эшләр белән алыштырырга мөмкин.

Ялкау тормыш рәвешенә ияләшеп, кеше җаваплылыктан һәм тырышлык таләп иткән җитди эштән качу турында уйлый. Димәк, ул чыннан да Аллаһы Тәгалә биргән сәләтләрне һәм мөмкинлекләрне куллланудан баш тарта, файдалы гамәлләр өчен бирелгән мөмкинлекләрне белә торып кулдан ычкындыра.

Ялкаулык шулай ук кешенең ниндидер кирәкле һәм файдалы эшне тәнкыйтьли башлавына китерә ала, чөнки аңа анда катнашудан котылу өчен сәбәп табарга кирәк. Димәк, ялкаулык ялган, алдау, хыянәт, куркаклык кебек гөнаһларга юл ача һәм кешеләргә китерә алган ярдәмнән генә түгел, ә аларның иң мөһим хокукларын саклаудан да баш тарттыра.

Һәрбер күренешнең нигезе булган кебек үк, ялкаулыкның да сәбәпләре бар, һәм аларның иң куркынычларының берсе – икейөзлелек. Коръәндә Раббыбыз икейөзлеләрне болай тасвирлый:

إِنَّ الْمُنَافِقِينَ يُخَادِعُونَ اللَّهَ وَهُوَ خَادِعُهُمْ وَإِذَا قَامُوا إِلَى الصَّلَاةِ قَامُوا كُسَالَىٰ يُرَاءُونَ النَّاسَ وَلَا يَذْكُرُونَ اللَّهَ إِلَّا قَلِيلًا

**«Һичшиксез, монафикълар Аллаһыны алдамакчылар. Хәлбуки, Ул аларның үзләрен алданган килеш калдырыр. Алар намазга баскан чакта, иренеп кенә басалар.** [Укыган намазлары белән дә Аллаһының ризалыгын өмет итмичә] **Кешеләргә үзләрен күрсәтәләр һәм Аллаһыны бик аз зикер итәләр».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:142

Ялкаулыкның сәбәпләре арасында эшне башкаруны соңгарак калдыру гадәте дә бар. Бу, кызганыч, күпләребезгә хас әйбер. Еш кына без бүген эшләргә кирәк эшебезне иртәгәгә калдырмаска өйрәнүнең мөһимлеген

аңлап бетермибез. Бу бигрәк тә тәүбә итү кебек мөһим гамәлләр турында сүз барганда әһәмиятле. Иртәгәсе көн безнең өчен килеп җитмәскә дә мөмкин, моны һәрвакыт истә тотарга кирәк.

Шулай ук җитди булмаган, әмма шулай да игътибарга лаек сәбәпләр дә бар. Бу, мәсәлән, уянганда Аллаһыны искә алмау. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе хәбәр итә: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Сезнең берәрегез йоклап киткәч, шайтан аның башына өч төен бәйләп куя һәм: «Төн озын булыр, йокла», — дип әйтәдер. Әгәр дә кеше уянып, Аллаһы Тәгаләне искә алса, бер төен чишелер; әгәр дә ул тәһарәт алса, икенче төен чишелер; ә әгәр дә ул намаз укыса, барлык төеннәр дә чишелер һәм иртән кеше күтәренке һәм яхшы кәефтә булачак. Юк икән — ул иртән начар кәефтә булыр һәм ялкауланыр»[1].

Күпләр уйламаган тагын бер сәбәп – артык ашау. Бик туклыклы төшке яки кичке аштан соң кеше ял итә, аны йокыга этәрә башлый. Аның Коръән укырга, төнге намаз укырга, файдалы белем алырга хәле калмый. Ислам һәрнәрсәдә дә урталыкка өнди. Һәм бу очракта урталык ялкаулык белән көрәшергә һәм вакытны исраф кылмаска ярдәм итеп, зур файда китерә.

Ялкаулыкның тагын бер сәбәбе — тәкъдир мәсьәләсен дөрес аңламауда. Шундый кешеләр очрый: алар барысы да Аллаһы Тәгалә тарафыннан алдан билгеләнгәнгә күрә, гамәл кылу да файдасыз, дип уйлыйлар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Безнең һәрберебезнең ахыры Аллаһыга билгеле булгач, ни өчен эшләргә кирәк?» — дип сорагач, ул болай дип җавап бирә: «Хезмәт итегез, чөнки сезнең һәрберегезгә яратылган нәрсәгә юл җиңеләйтелә»[2]. Башкача әйткәндә, кеше үзе үзенең тормыш тарихын яза, ул Аллаһы Тәгаләгә билгеле булса да, кешенең үз ихтыярына һәм аның сайлавына бәйле.

Ялкаулык белән ничек көрәшергә? Әлбәттә, Аллаһыга ялварып дога кылыгыз! Икенчедән, Аллаһы Тәгалә безгә игелекле эшләрдә катнашырга

---

1 Әл-Бохари, Мөслим.

2 Әл-Бохари, Мөслим.

кушты. Дөньядагы тормыш бик кыска, һәм без аның кайчан өзеләчәген дә белмибез. Бу тормыш тырышып эшләр өчен, ә аннары, Аллаһының рәхмәтенә лаек булсак, чиксез оҗмахта ял итәрбез. Әллә без моңа омтылмыйбызмы? Өченчедән, игелекле эшләр башкарырга ашыгучы, үз вакытларын кадерләүче һәм аны дөрес куллана белүче җитди, эшлекле кешеләр белән күбрәк аралашырга кирәк. Яхшы мисал — зур этәргеч, стимул. Тормышлары гыйбадәт, файдалы хезмәт һәм игелекле эшләр белән тулы булган тәкъва кешеләрнең тормыш рәвешен өйрәнү дә ярдәм итә.

Ялкаулык — дәваланмаса, тиз үсә торган авыру. Киләчәктә үзегездә ялкаулык сизсәгез, Аллаһы Тәгаләнең әҗерен, тырышып эшләүчеләрне көткән оҗмахны, безнең өчен яхшы үрнәк булган кешеләрне һәм безнең иң явыз дошманыбыз — шайтанны — искә төшерегез, әгәр дә сез ялкаулыкка бирелсәгез, ул шатланачак. Ялкаулык белән көрәш ул — ике дөньяда да үз бәхетебез өчен көрәш.

Әй Аллаһым! Безгә ялкаулыкны җиңәргә һәм Синең ризалыгың өчен генә күбрәк яхшылыклар эшләргә ярдәм ит, шул рәвешле Син безнең белән канәгать булырсың, дип өмет итәбез!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәт хәзрәт Фәйзуллин,*

*Казанның «Иман Нуры» мәчетенең икенче имамы*

*26 нчы апрель вәгазе,*
*шәүвәл аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Телләр – Раббыбызның нигъмәте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы һәм барча мәхлукларын иксез-чиксез нигъмәтләре белән нигъмәтләндереп торучы бердәнбер Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә иксез-чиксез рәхмәтләребез һәм шөкраналарыбыз булса иде. Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, безгә Ислам дине буенча яшәп күрсәткән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан хәер-догаларыбыз, салаватшәрифләребез барып ирешсә иде. Ерак һәм якын җирләрдән изге җомга көнне Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәр өчен мәчетебезгә җыелдык.

Хөрмәтле мөселманнар! Барлык көннәрнең солтаны булган изге җомга бәйрәме барчаларыбызга да мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормыш насыйп итсен. Мөкаддәс җомга көнне ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булса иде!

Аллаһы Раббыбыз шушы матур җир йөзенә адәм балаларын, без, кешеләрне, Үзенең зур хикмәте белән, төрле-төрле кыяфәттә, төрле-төрле телләрдә аралашучы итеп барлыкка китерде.

Аллаһы Тәгалә изге Китабында әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне** [Адәм исемле] **бер ирдән һәм** [Хава исемле] **бер хатыннан яраттык.** [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] **Без сезне** [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] **танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез –** [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннанан сакланган] **бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы –** [һәрнәрсәне] **Белүче,** [һәрнәрсәдән] **Хәбәрдар».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Без, адәм балалары, нинди милләт вәкиле булуыбызны, кайсы җирлектә бу дөньяга барлыкка килүебезне, нинди телдә сөйләшүебезне, тән төсебезне, кыяфәтебезне, әти-әниләребезне, нәсел-нәсәбебезне үзебез сайлап алмадык. Болар барысы да Аллаһы Раббыбызның безгә биргән бүләге. Безнең изге бурычыбыз – Аллаһыдан бирелгән шушы зур бүләкләрне кадерләп, саклап тоту һәм иң мөһиме – шушы нигъмәтләрне Бирүчегә рәхмәтле булып яшәвебез.

Барлык хикмәт безнең туган телебез белән беррәттән төрле телләрне, халыкларны һәм кабиләләрне өйрәнүдә. Хәзрәт Зәед бине Сәбит радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бервакыт пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа яһүдләрнең телен өйрәнергә әмер итте. Ярты айдан мин инде бу телдә язарга өйрәндем. Шулай итеп, телне өйрәнеп, мин яһүдләргә хатлар язып, килгән хатларны укый идем»[1].

Бу хәдистә яшь сәхабә Зәед бине Сәбит радыяллаһу ганһегә әмер бирүе белән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә

1 Әл-Бохари.

башка телләрне өйрәнүнең зур әһәмияткә ия булуын күрсәтә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһының рәхмәте белән алдан ук Исламның көнчыгыштан көнбатышка кадәр, ягъни барлык җир йөзенә таралачагын белә торып, төрле халыкларның телләрен өйрәнүне бу зур максатка ирешүнең бер юлы икәнен күрсәткән. Һичшиксез, танышу, башка милләтләрнең үзенчәлекләрен өйрәнү, үзеңнең фикереңне, рухи тәрбия мәсьәләләрен, гүзәл динебезнең кыйммәтле фикерләрен башка халыкларга җиткерү өчен шушы халыкның телен белү – ул иң көчле корал булып тора. Шул сәбәпле туган теле белән беррәттән чит телләрне дә белгән кеше бәхетсез булмас.

«Чит телләрне күп бел, ләкин үз телеңне онытма» — шул сәбәпле, чит телләрне өйрәнә башлаганчы, кеше бишектән үк әни телен сеңдерергә тиеш. Аннан соң чит телләрне күпме тели, шуның кадәр өйрәнергә хаклы. Шул тәртип сакланса, саф ана теле һәм милләтнең дәрәҗәсе дә сакланыр. Ана телен оныткан халык хурлыкка калыр һәм юкка чыгар. Үз телен белгән кешегә чит телне өйрәнү дә җиңелрәк бирелер. Бу мәсьәлә әти-әниләр өстенә үз балаларының тәрбиясен беренче чиратта ана телендә алып баруны бурыч итеп куя.

«Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы», — үзенең туган телгә мәхәббәтен татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай әнә шулай матур итеп әйтеп биргән. Туган телне юкка гына «ана теле» дип атамаган шул халык! Гасырлар буе чит милләтләр һәм телләр мохитендә яшәп тә, үз телләрен саклап килүче, аны хәтта милләтнең таныклыгы итеп санаучы халыклар бар. Мисал өчен, Австралия аборигеннары яисә Төньяк Ирландиялеләр. Австралиядә бер тел белгече: «Үз телебездә сөйләшмәгән вакытта без үзебезне юк дип хис итәбез», — ди. Аларның үз телләрен изге догага тиңләүләре – аларның үз мәдәниятләрен саклап калырга тырышулары.

Җирнең теләсә кайсы почмагына барып, андагы халыклар белән аралашу өчен галимнәр 14 тел белү җитүен һәм алар арасында татар теле дә бар-

лыгын әйтә. Чит телләрне, һәр гыйлем кебек үк, яшь вакытта өйрәнә башлау күпкә уңышлырак булыр, чөнки яшь кешенең хәтере, игътибары көчлерәк була. Гарәпләрдә бу мәсьәләгә кагылышлы мондый әйтем бар: «Яшь вакытта алган гыйлем ташка ясалган бизәк кебек, картлыкта алган гыйлем бозга ясалган бизәк кебек». Алда искә алынган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәрҗемә итү мәсьәләләрен башка милләт вәкилләренә тапшырмаганлыгы күренә. Фикерләүчеләр өчен монда да зур гыйбрәт бар.

Аеруча зур игътибарга дәүләтара, илара әңгәмәләр лаек, мондый очракларда күп халыкларның мәнфәгатьләре күздә тотыла. Чит илдән килгән тәрҗемәченең авызына карап утырганчы, әлбәттә, үз тәрҗемәчеләреңә ышаныч зуррак. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең максаты барлык милләт вәкилләре белән дә яхшы мөнәсәбәттә тору белән барлык халыкка да хакыйкый динне җиткерү була. Безгә дә дөньяга Ислам диненең гүзәллеген, мөһим булган кыйммәтләрен, Аллаһының хакыйкый динендә бернинди дә экстремизм, терроризм юк икәнлеген җиткерү өчен, чит телләрне югары дәрәҗәдә, камил рәвештә өйрәнү бурычы ята.

Борынгы бабаларыбыз, татар галимнәребезнең тормыш юлларына күз салсак, аларның 4–5, хәтта кайберләре күбрәк тә телдә җиңел аралашуларын күрә алабыз. Мәсәлән, татар зыялысы Каюм Насыйри телләрне бик яхшы белгән: татар, гарәп, фарсы, рус телләрендәге китапларны укый алган. Тагын бер мисал итеп, данлыклы Иж-Бубый мәдрәсәсе мөгаллиме Габдулла Бубыйны китереп була. Аның турындагы истәлекләрдә ул татар, рус, гарәп, төрек, фарсы, француз һәм уйгыр телләрен мөкаммәл белгән, дип китерелә.

Күп очракта кеше үзенең мәхлук икәнлеген, һәм барлыкка китерелүенең төп максаты галәмнәрнең Раббысына гыйбадәт кылу икәнен онытып җибәрә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Милләтчелеккә чакыручы — бездән түгел, милләтчелек өчен сугышучы — бездән түгел, милләтчелек өчен вафат булган кеше – бездән түгел»[1].

Һәрберебез яхшы аңларга тиеш, без барыбыз да — Аллаһының коллары, кем дә кем кешеләрне тән төсенә яки милләтенә карап бүлә башлый икән, димәк, ул – тәккәберлекнең бер күренеше һәм мондый кеше Аллаһының кануннарына каршы килә дигән сүз.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына** [Китабына һәм диненә] **ныклап ябышыгыз һәм** [әһле китап кебек ихтилафка төшеп, хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] **аерылмагыз».**

«Әлү Гыйимран / Гыйимран гаиләсе», 3:103

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм соңгы хаҗы вакытында: «Гарәпнең гарәп булмаган кешедән өстенлеге юк, фәкать тәкъвалыкта гына», — дип әйткән[2].

Шулай ук сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында булган олуг сәхабәләр арасында төрле тән төсендә, төрле милләттә, җәмгыятьтә төрле дәрәҗәдә урын тотканнары булганнарын беләбез. Ләкин алар бердәм, дус һәм тату булдылар. Алар арасында ызгыш-талашлар булмады. Алар безгә зур үрнәк булдылар.

---

1 Әбү Давыд.

2 Имам Әхмәд.

Олуг хаҗ гыйбадәте дә Ислам динендә күп милләтләрнең бергә-бергә дус-тату мөгамәлә кыла алуларына ачык мисал.

Аллаһы Раббыбыз араларыбызга өлфәт мәхәббәт, бер-беребезгә хөрмәт күрсәтеп, дус-тату булып яшәүләребезне насыйплардан әйләсә иде. Ислам динен дөрес итеп аңларлык гыйлем-зиһен бирсә иде. Төрле фетнәләрдән, ызгыш-талашлардан, сугыш афәтләреннән имин кылса иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илнур хәзрәт Фәрхетдинов,*
*Тукай районы Күзкәй авылы имам-хатыйбы*

*3 нче май вәгазе,*

*шәүвәл аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең «Әл-Фәттах» исеме

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Хуҗасы булган, киң рәхмәте илә безне тәрбияләп торган, хата вә кимчелекләребезне гафу итеп, безне туры һидаять юлыннан алып барган Җәнәбел-Хак Аллаһы Раббүл Гыйззәгә ихлас күңелләребездән чыккан хәмед-сәналәребез, мактауларыбыз, олуглауларыбыз ирешә күрсә иде. Бөек Илаһыбыз ике җомга арасында кылынган гыйбадәт-гамәлләребезне кабуллардан кылса иде! Барча галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, галәмнәрнең нуры булган бөек шәфәгатьчебез, сөеклебез, хәбибебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез вә салават-шәрифләребез ирешә күрсә иде!

Хөрмәтле газиз мөэмин-мөселман кардәшләрем, Җәнәбел-Хак Аллаһы Раббыбыз үзенең Кәлам Шәрифендә «Әл-Әгъраф» сүрәсенең 180 нче аятендә шулай боера ки:

وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَىٰ فَادْعُوهُ بِهَا

**«Аллаһыда –** [иң матур һәм иң шәрәфле мәгънәләрне белдергән] **күркәм исемнәр. Аңа шулар белән ялварыгыз».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:180

Аллаһы Раббыбызга чиксез хәмед-сәналәр булсын, Аның күркәм, бөек исемнәрен укып, ятлап, алар илә дога кылып, Җәнәбел-Хак Аллаһы Раббыбызга якынаябыз, Аның ризалыгына омтылабыз.

Бүгенге җомга вәгазебез Җәнәбел-Хак Аллаһы Раббыбызның күркәм исемнәренең берсе, «Әл-Фәттах» исеме турында булачак, иншәАллаһ. Шушы күркәм исемнең мәгънәләрен аңлатырга тырышырбыз, Аллаһының ярдәм вә рәхмәте илә.

«Әл-Фәттах» — «ачучы», «ачып җибәрүче», «җиңү бирүче» дигәнне аңлата.

«Сәбә» сүрәсенең 26 нчы аятендә Галәмнәрнең Хуҗасы боера ки:

قُلْ يَجْمَعُ بَيْنَنَا رَبُّنَا ثُمَّ يَفْتَحُ بَيْنَنَا بِالْحَقِّ وَهُوَ الْفَتَّاحُ الْعَلِيمُ

«[Расүлем!] **Әйт: «**[Кыямәт көнендә] **Раббыбыз арабызны берләштерәчәк, шуннан соң** [бернинди золымга дучар итмичә] **арабызда хак белән хөкем бирәчәк. Ул бит – Игелек** [һәм бәрәкәт] **капкаларын ачучы,** [һәрнәрсәне] **Белүче».**

«Сәбә», 34:26

Ягъни авыр хәлдә калган бәндә, әгәр дә бөтен күңеле белән Аллаһыга ялварса, Аңарда ярдәм эзләсә, тәкъвалык күрсәтсә, һичшиксез, Раббыбыз аңа авырлыкны җиңеллек белән, кайгыны шатлык белән вә тынычсызлыкны тынычлык, сәкинәт белән алыштырачак. Авыр хәленнән чыгыш юлларын ачачак, Үзенең рәхмәт, игелек, бәрәкәт капкаларын аның алдында ачып куячак, дошманнары өстеннән җиңү бирәчәк.

«Әт-Талак» сүрәсендә Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

وَمَن يَتَّقِ اللَّهَ يَجْعَل لَّهُ مَخْرَجاً ۝ وَيَرْزُقْهُ مِنْ حَيْثُ لَا يَحْتَسِبُ وَمَن يَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُ إِنَّ اللَّهَ بَالِغُ أَمْرِهِ قَدْ جَعَلَ اللَّهُ لِكُلِّ شَيْءٍ قَدْراً

**«... Кем дә кем Аллаһыдан курыкса, Ул аңа** [үлем куркынычлыгыннан, Кыямәт көненең кыенлыкларыннан] **бер чыгыш** [юлы] **насыйп итә. Һич көтмәгән ягыннан аны ризыкландыра. Кем дә кем Аллаһыга тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә. Һичшиксез, Аллаһы һәрнәрсә өчен** [ул әле бар булганчы] **бер үлчәм куйган».**

«Әт-Талак», 65:2–3

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе ошбу аятьне аңлатып, шулай дигән: «Ягъни Аллаһы шул кешене ике дөнья кайгысыннан имин кылыр вә ике дөнья бәхетенә ирештерер».

Шулай ук Аллаһы Үзенең бәндә-колларына һидаять, мәгърифәт, мәхәббәт капкаларын ачучы. Ул Үзенең чиксез рәхмәте илә колларын һидаять нуры белән нурландыра, аларның калеб-күңелләренең капыларын ачып, шунда мәгърифәт вә мәхәббәт урнаштыра. Һәрбер колына хәерлелек, бәрәкәт тели, әгәр колы тыелган эшен, кәсебен Аллаһы ризалыгы өчен калдырса, Ул аңарга башка хәләл кәсеп юлларын, бәрәкәт ишекләрен ачачак.

Һәм шулай ук Аллаһы Раббыбызның ошбу исме-шәрифе «Хөкемдар, Хөкем итүче» мәгънәсендә китерелә. «Әл-Әгъраф» сүрәсенең 89 нчы аятендә Галәмнәрнең Хуҗасы боера ки:

رَبَّنَا افْتَحْ بَيْنَنَا وَبَيْنَ قَوْمِنَا بِالْحَقِّ وَأَنتَ خَيْرُ الْفَاتِحِينَ

**«... Ий Раббыбыз! Безнең белән кавемебез арасында хак** [һәм гаделлек] **белән хөкем бир. Син бит – хөкем бирүчеләрнең иң яхшысы.** [Чөнки бер генә хөкемеңдә дә золым һәм гаделсезлек юк]**».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:89

Бөек галим имам Катәдә ошбу аятьне: «Без вә кавемебез арасында гадел, хак хөкем ит», — дип аңлата.

Әл-Фәттах ул — коллары арасында гаделлек вә хаклык белән хөкем итәчәк Зат. Җәнәбел-Хак Аллаһы Раббыбыз Үзенең колларына тузан

бөртеге хәтле дә золымлык кылмый, «Ән-Ниса» сүрәсенең 40 нчы аятендә болай диелә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ ۖ وَإِن تَكُ حَسَنَةً يُضَاعِفْهَا وَيُؤْتِ مِن لَّدُنْهُ أَجْرًا عَظِيمًا

**«Һичшиксез, Аллаһы бер** [кешенең казанган савабын киметеп яки тиешеннән артык газап биреп] **зәррә авырлыгы кадәр дә золым итмәс. Әгәр ул** [гамәл] **яхшы бернәрсә икән, Ул аны** [савап ягыннан] **арттырыр һәм Үз хозурыннан бик зур әҗер бирер».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:40

Раббыбыз «Әт-Тин» сүрәсендә шундый сорау бирә:

أَلَيْسَ اللَّهُ بِأَحْكَمِ الْحَاكِمِينَ

**«Хөкем бирүчеләрнең иң дөрес хөкем биргәне Аллаһы түгелме?** [Эш болай икән, Кыямәт көнендә коллар арасында тиешле хөкемне Ул бирәчәк]**».**

«Әт-Тин / Инҗир», 95:8

Әлбәттә, безнең җавабыбыз бер: һичшиксез, хөкем бирүчеләрнең иң гаделе вә иң дөрес хөкем бирүче — Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә!

Имам әс-Сануси хәзрәтләре ошбу исме-шәриф турында: «Аллаһының гаять гүзәл исеме — Әл-Фәттах — авыр, сынаулы, фетнәле вакытларда дөнья вә Ахирәт өчен изгелекләр кылырга, хәерле гамәлләр башкарырыга җиңеллек бирүче дигәнне аңлата», — дип яза.

Газиз дин кардәшләрем, чыннан да, тарихыбызга һәм бүгенге көнгә баксак, без сынау заманасында яшәп киләбез. 1945 елның 9 нчы маенда безнең бабаларыбыз бөтен җир шарына, «әл-фәтх», ягъни Җиңү вә тынычлык китерделәр. Әйтеп киткәнчә, Аллаһы Раббыбыз Ул — Әл-Фәттах, Җиңү бирүче, бүген без дә колларыбызны күтәреп, изгелекләр башкарып,

Раббыбызга ялварыйк. «Әл-Фәтх» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّا فَتَحْنَا لَكَ فَتْحًا مُّبِينًا

**«Һичшиксез, Без сиңа ап-ачык җиңү насыйп иттек».**

«Әл-Фәтх / Җиңү», 48:1

«Әл-Бәкара» сүрәсенең 214 нче аятендә Раббыбыз безгә болай дип әйтә:

أَمْ حَسِبْتُمْ أَن تَدْخُلُوا الْجَنَّةَ وَلَمَّا يَأْتِكُم مَّثَلُ الَّذِينَ خَلَوْا مِن قَبْلِكُم ۖ مَّسَّتْهُمُ الْبَأْسَاءُ وَالضَّرَّاءُ وَزُلْزِلُوا حَتَّىٰ يَقُولَ الرَّسُولُ وَالَّذِينَ آمَنُوا مَعَهُ مَتَىٰ نَصْرُ اللَّهِ ۗ أَلَا إِنَّ نَصْرَ اللَّهِ قَرِيبٌ

**«**[Ий Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Өхедтә һәм Хәндакта кыенлык чиккән сәхабәләр!] **Әллә сез үзегездән алда килеп киткәннәргә төшкәннәр** [авырлыклар] **сезгә дә килми торып, җәннәткә керербез дип уйлыйсызмы? Аларга** [фәкыйрьлек, ярлылык кебек] **мохтаҗлык һәм** [авыру, курку кебек] **кайгы-хәсрәтләр кагылды, алар** [төрле бәлаләр аркасында] **тирән тетрәнүләр кичерделәр ки,** [ахыр чиктә ул заманның иң сабыр һәм чыдам кешесе булган] **пәйгамбәр һәм аның белән иман китерүчеләр дә** [Аллаһы Тәгаләнең ярдәме соңламасын дип]**: «Аллаһының ярдәме кайчан** [килер соң]**?» — дияләр иде.** [Менә шул вакыт, догаларны кабул итеп, Аллаһы Тәгалә тарафыннан аларга:] **«Белегез: һич шик юк, Аллаһының ярдәме бик якын!»** [дип әйтелде]**.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:214

Әлеге аять хөрмәтенә, газиз Ватаныбызга хәерле җиңү насыйп кылсын, ил-көннәребезгә тынычлык вә иминлек насыйп итсен. Бөек Илаһыбыз,

бердәнбер Раббыбыз, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барчабызга да бәхет-шатлык, ике дөнья хәсәнәтенә ирешүләрне насыйп кылсын. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Сәүбән,*
*Тукай районы имам-мөхтәсибе*

*10 нчы май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Җомга көне әдәпләре

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар итүче, яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барлык хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле колы, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барча салават-шәрифләребез ирешсен.

Хөрмәтле җәмәгать, Аллаһы Тәгалә изге җомга көнен биреп, безне зур нигъмәт белән бүләкләгән. Һәр җомгада без моны искә алып, кабатлап торырга тырышабыз. Бүгенге вәгазебездә мөбарәк булган җомга көненә кагылышлы кайбер мәсьәләләргә аерым тукталып, аларны санап китик.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә җомга көнен шулкадәр ярата, аны башкаларыннан аерып ала ки, хәтта Коръәндә аның исеме белән аталган «Җомга» сүрәсен иңдерә. Сүрәләргә исемнәр очраклы рәвештә бирелмәгән. Аллаһы Тәгалә Үзе безне һәрбер әйберне исемнәр белән атарга өйрәткән. Мәсәлән, «Әл-Бәкара» — «Сыер» сүрәсе дип аталган. Әйе, галимнәр: «Анда сыер турында тарихлар бар», — дип әйтәләр. Сүрәләрнең күбесендә исемнәренә карап, аның тарихын күрергә була. Ә кайбер сүрәләргә бер төрле исем бирелгән, ләкин аның эчендә ул исемгә туры килгән бер генә сүз дә булмаска мөмкин. Аның шулай аталуы — Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең әмере. Күп кенә сүрәләрнең икедән күбрәк исеме бар, бу сан унга кадәр дә җитәргә мөмкин.

«Җомга» сүрәсенә килгәндә, әлеге сүрә нәкъ тә җомга көненә багышланган. Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә анда бу көнгә караган әдәпләрне әйтеп үтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ

**«Ий иман китерүчеләр! Җомга көнне намаз өчен** [азан әйтелеп] **чакырылгач, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз һәм сәүдәне ташлагыз. Бу —** [сәүдәнең вакытлы файдасыннан] **сезнең өчен яхшырак. Әгәр дә белсәгез иде** [мәңгелек алыш-бирешне сайлар идегез]**».**

«Җомга», 62:9

Әлеге аять безгә намаз вакыты җитүгә, бөтен эшегезне ташлагыз, Аллаһы йортына, мәчеткә җомгага барыгыз, ди. Ни өчен монда Аллаһы Тәгалә нәкъ тә сәүдә турында әйтә? Сәүдә белән шөгыльләнгән кешегә сатылган товардан кергән керем бик мөһим булып тора. Нәтиҗәдә, ул үзенә керем дә, ләззәт тә ала. Раббыбыз безне нәкъ тә ахирәт өчен, Аны искә алыр, Аңа зикерләр әйтер өчен шушы дөнья ләззәтләреннән туктата һәм «бу сезнең өчен хәерлерәк булыр» ди. Барыбыз да белә: җомга көнне шулай ук гадәттәгечә биш фарыз намаз укыла, ләкин өйлә намазы вакытында мәчетләрдә җәмәгать белән җомга намазы кылына. Аның тәртибен өммәтебезгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп, күрсәтеп калдырган. Җомга намазы 4 рәкәгать сөннәт, 2 рәкәгать фарыз, 4 рәкәгать сөннәттән гыйбарәт.

Шулай ук Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә җомга көненә бик игътибарлы булып, аның аерым әдәпләрен үтәргә дә киңәш итеп калдырган. Мәсәлән, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем җомга намазына барырга уйласа, госел алсын» яки «Җомга җитсә, госел алыгыз», — дип әйткән. Әлеге фикернең икесе дә дөрес булып тора.

Хәдисләрдән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җомга көненә төнлә үк әзерләнә башлавы билгеле. Ул бик яхшылап юынып, госел алган. Иртән иң пөхтә, матур киемнәрен киеп, исле майлар кулланган, чәчләрен тараган. Кирәк булса, ул сакалын тигезләгән, чәчләрен кыскарткан,

тырнакларын кискән. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрдаим йөрәге белән дә, теле белән дә Раббыбыз Аллаһыга зикер-тәсбихләр әйтеп торган. Болар аның җомга көнен ничек яратуын, хөрмәт итүен күрсәтеп, безнең өчен камил үрнәк булып тора. Җомга көненең аерым тагын бер күркәм сөннәте ул — Коръәни Кәримнең 18 нче сүрәсе, «Әл-Кәһф» сүрәсен уку. Хөрмәтле җәмәгать, без, кызганыч, бу әйберләргә кайвакыт бик аз игътибар бирәбез.

Киләсе хәдисне дүрт бөек имамнарның берсе, диннең терәге булган хәдисләрне җыйган галим Әхмәд бине Хәнбәл китерә. Без имам Әхмәднең «Мөснәд»ендә уйлап чыгарылган хәдисләр юк, барысы да ныклы икәненә ышанабыз. Дөньядагы барлык мөселманнар: хәнәфиләр, шәфигыйләр, мәликиләр, хәнбәлиләр — барысы да Имам Әхмәднең әлеге хәдисләр җыентыгына мөрәҗәгать итәләр. Бу хәдис сөннәт гамәлләр турында гына түгел, ә шәригать ягыннан төгәл рәвештә үтәлергә тиешле гамәлләр хакында.

Димәк, җомга намазы турындагы бу хәдисендә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җомга көнне имам хотбә әйткән вакытта кем дә кем сөйләшеп утыра, әлеге гамәле белән ул китап ташучы ишәк кебек», — дигән. Җәмәгать, без моннан бик сак булырга тиеш! Шушы хәдисне дәвам итеп ул: «Янындагы кешенең аны туктатырга тырышырга да хакы юк», — дигән. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, бу хәдистән без шуны аңлый алабыз: Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хотбә вакытында бер генә кешегә дә бер генә сүз дә сөйләргә рөхсәт итеп калдырмаган.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр имам минбәргә менде икән, намаз уку ярамый. Ә имам минбәргә чыгып басканчы, башына нинди намаз кылә, шунсын укысын. Әгәр ул имамның чыкканын һәм утырганын күрсә, имам җомганы һәм сүзләрен үтәп бетергәнчегә кадәр сөйләшмичә торсын», — дигән.

Киләсе хәдистә болай диелгән: «Кем дә кем гозерсез өч җомганы калдырган икән, ул монафикълар арасында язылган булыр»[1]. Аллаһы Раббыбыз моннан Үзе сакласын!

Шулай итеп, кадерле дин кардәшләрем, шушы хәдисләрне истә тотып, тормышыбызда да аларны кулланырга кирәк, чөнки әлеге хәдисләр барысы да Имам Әхмәднең «Мөснәд»ендәге, шәригатьтә, фикһта кулланыла торган хәдисләр. Аларны бер мәзһәб вәкиле дә кире кага алмый, чөнки күркәм гамәлләргә этәрә торган хәдисләрне кертмәгән, фәкать Аллаһы һәм Аның коллары арасында булган мөгамәләгә кагылышлы, шәригатьтә язылган, кулланып була торган хәдисләрне керткән. Болар – җомгабыз каршында үзебезнең гамәлләребезне дөресләү өчен безгә зур мөмкинчелек.

Хөрмәтле җәмәгать, Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәрбарчабызга да туры юлдан тайпылмыйча, Раббыбыз кушканнарны үтәп, тыйгannardан тыелып, Аның ризалыгына омтылып яшәргә насыйп итсен. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин,*
*Казанның «Котдус» мәчете имам-хатыйбы*

[1] Әт-Табәрани.

*17 нче май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ислам финанслары

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен.

Безнең барыбызга да мәгълүм: бу дөнья фәкать бер Аллаһыга гына буйсына һәм бары тик Ул гына аның белән идарә итә. Ә безне, адәм балаларын, Ул бу дөньяда хәлифәләр итеп билгеләде һәм бу хакта Раббыбыз Аллаһы Коръәни Кәримдә хәбәр итә:

إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً

**«...Һичшиксез, Мин җирдә хәлифә** [итеп Адәмне [галәйһиссәлам] **яратачакмын!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:30

Бу җирдә хәлифә ник кирәк соң? Аллаһы Адәм галәйһиссәламне һәм аның нәсел дәвамчыларын хәлифә – җирдәге эшләргә идарәче, табигатьне саклаучы, мохтаҗларга ярдәм итүче, җәмгыять эшләрен оештыручы зат – итеп билгеләде. Ул, кеше буларак һәм гомумән тулы бер җәмгыять буларак та Аллаһы Тәгалә әмерләренә буйсынып яшәсен өчен, Аллаһы кушканнарны үтәп, Ул тыйганнардан тыелып яшәсен өчен. Моңа «Әз-Зарият» сүрәсенең 56 нчы аяте күрсәтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Шуны әйтеп үтәргә кирәк, гыйбадәт ул намаз кылу, ураза тоту гына түгел, бу төшенчә күпкә киңрәк. Әгәр фикһ китапларына мөрәҗәгать итсәк, аларда финанс мәсьәләләренә караган бүлекләр зур урын алып тора. Бу өлкәгә ни өчен шундый зур игътибар бирелә соң, дигән сорау да туарга мөмкин.

Белүебезчә, динебез буенча бар кешеләр дә тигез: бер кеше дә, җәмгыятьтәге дәрәҗәсе яки ниндидер бер милләт вәкиле булуына карап, башкалардан өстен була алмый, чөнки Аллаһы Раббыбыз безне бер җаннан бар кылды һәм бу хакта «Ән-Ниса» сүрәсенең 1 нче аятендә болай диде:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ

**«Ий кешеләр! Сезне бер җаннан** [Адәмнән] **яраткан, аның бер кисәгеннән** [булган сул кабыргасының иң астыннан Хава исемле] **ишен яраткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны халык кылып** [җиһанга] **тараткан Раббыгыздан куркыгыз».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:1

Коръәндәге бу сүзләр исебезгә төшерә: кем генә булсак та, без барыбыз да бер тамырдан, бер үк ата-анабызның балалары. Моңа карата шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәребезнең хәдисе билгеле: «Ий кешеләр! Дөреслектә, сезнең Раббыгыз бер, сезнең атагыз бер. Сез барыгыз да Адәмнән барлыкка

килгән, ә Адәм — балчыктан. Гарәп милләтеннән булганның гарәп булмаган кешедән өстенлеге юк»[1].

Димәк, безнең бөтен үзара мөнәсәбәтләребез, бәйләнешләребез тигезлек һәм намуслылыкка нигезләнгән булырга тиеш. Һәм шул рәттән икътисад, ягъни экономика, сәүдә мәсьәләләре дә. Динебез Ислам сәүдә һәм мөнәсәбәтләрне гадел рәвештә корырга өнди.

Һәм моңа иң ачык мисал булып рибаның тыелуы тора. Нәрсә соң ул риба? «Риба» дип тыелган килешүләрнең кайбер төрләренә яки шулардан килгән керемгә әйтәләр. Рибаның иң таралган төре ул — ссудалы процент, ягъни кредитка (бурычка) бирүдән керем алу. Гади генә әйткәндә, мәсәлән, Гали Бәкергә бурычка 1000 сум акча бирде, һәм Бәкер аңа 1200 сум итеп кайтарырга тиеш булачак, дигән шарт куйды. Шушы 200 сум керем риба, ссудалы процент булып тора да. Шәригатебездә риба катгый тыелган.

Билгеле булганча, инде борынгы заманнардан кешеләр керем алу максаты белән бурычка акча бирә торган була. Мондый гадәт Гарәбстан ярымутравында да була. Шуңа бәйле Раббыбыз рибаны катгый тыеп, «Әл-Бәкара» сүрәсендә болай дигән:

الَّذِينَ يَأْكُلُونَ الرِّبَا لَا يَقُومُونَ إِلَّا كَمَا يَقُومُ الَّذِي يَتَخَبَّطُهُ الشَّيْطَانُ مِنَ الْمَسِّ ۚ ذَٰلِكَ بِأَنَّهُمْ قَالُوا إِنَّمَا الْبَيْعُ مِثْلُ الرِّبَا ۗ وَأَحَلَّ اللَّهُ الْبَيْعَ وَحَرَّمَ الرِّبَا ۚ فَمَن جَاءَهُ مَوْعِظَةٌ مِّن رَّبِّهِ فَانتَهَىٰ فَلَهُ مَا سَلَفَ وَأَمْرُهُ إِلَى اللَّهِ ۖ وَمَنْ عَادَ فَأُولَٰئِكَ أَصْحَابُ النَّارِ ۖ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ

**«Риба ашаучылар** [каберләреннән] **шайтан сугып еккан тиле кеше газапланган кебек кубарылырлар. Бу** [җәза] **аларга: «Сату-алу да риба кебек бит», – дигәннәре өчен. Хәлбуки, Аллаһы сату-алуны хәләл итте** [акчаны акчага алыштырганда яки бер үк төрле малларны

---

1 Имам Әхмәднең «Мөснәд» җыентыгы, 5/411.

> алмашканда], **рибаны исә харам кылды. Кем дә кем Раббысыннан аңа** [рибаны тыйган] **үгет-нәсыйхәт килгәннән соң,** [аңа ияреп, ялгышыннан] **ваз кичә, үткән нәрсә – аның үзе өчен** [рибадан алганнары соралмый]**. Аның эше – Аллаһыга** [калдырыла]**. Кем дә кем** [рибаны хәләл дип кабул итү фикеренә] **кайта, алар – Ут әһелләре. Алар – анда мәңге калучылар».**
>
> «Әл-Бәкара / Сыер», 2:275

Бу аять риба белән акча табып яшәүчеләргә зур кисәтү булып тора.

Шулай ук рибаның тыелуында әхлакый як та бар: әгәр кеше әҗәткә акча сорарга мәҗбүр икән, димәк, ул кыен хәлдә калган. Ә кешенең кайгысында яки кыен хәлендә акча эшләү — әхлакка бер дә туры килми. Исламның әлеге кануны ике якны тигезләүгә, бер кешенең икенчесенең мохтаҗлыгында акча эшләмәвенә юнәлтелгән. Динебез икътисади мөнәсәбәтләрдә тигезлек һәм намуслылыкка өнди.

Бүгенге көнгә, безнең вакытка карасак, илебездә ислам финанслары актив рәвештә үсә. Дәүләтебез шулай ук бу проектка булышлык күрсәтә. Россиянең аерым субъектлары, шул чиратта җөмһүриятебез Татарстан да, РФ Дәүләт думасы тарафыннан расланган партнерлык (ислам) финанслау экспериментында катнаша. Дәүләт тарафыннан мондый проект ашырылуы аның мөселманнарга әлеге эшендә ярдәм итүен һәм ислам финансларын үстерүнең әһәмиятен аңлавын күрсәтә.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, бу өлкәдәге эш дәүләт эчендә генә алып барылмый, башка илләр белән бәйләнешләр булдырыла. Мәсәлән, «Россия — Ислам дөньясы: KazanForum» дип аталган Халыкара икътисад форумы кысаларында ислам финансларына караган актуаль мәсьәләләр күтәрелә. Бу форумда төрле ислам дәүләтләре вәкилләре катнаша, алар актив үсә, сәүдә һәм финанс өлкәсендә, инновацияләр һәм фәнни-гамәли тикшеренүләрдә зур нәтиҗәләргә ирешә. Ә безнең илебез алар белән эш һәм гуманитар хезмәттәшлеккә ачык. Быел әлеге «Россия — Ислам дөньясы»

форумы мәркәзебез Казанда 14–19 майда үтә. Әлеге форум белән беррәттән республикабыз мөселманнары өчен тагын бер мөһим һәм көтеп алынган вакыйга — Изге Болгар җыены уздырыла. Ел саен бу чарада Татарстан, чит төбәкләр һәм хәтта чит илләрдән килгән меңләгән мөселман кардәшләребез тарихыбызны искә төшерергә, бергә намаз һәм догалар кылырга җыела.

Мөселман дәүләтләреннән мондый чараларга игътибар булуы очраклы түгел. Бүгенге көндә Россия банклары тарафыннан уннан артык финанс продукт әзерләнгән һәм уңышлы гына эшләп килә. Алар тулысынча шәригать кануннарына туры килә. Алар арасында хәләл ипотека, лизинг, факторинг, «Лалә» инвестицион портфеле һәм башка продуктларны атап үтәргә мөмкин.

Мондый проектлар ислам финансларының үсү мөмкинлекләрен һәм шулай ук үзебезнең җирлектәге белгечләрнең әлеге эшне алып барырга сәләтле булуларын күрсәтә.

Кардәшләрем, без, Татарстан мөселманнары, мондый мөмкинлекләр ачылуына Раббыбыз Аллаһыга рәхмәтле булырга тиешбез. Ел саен мәчетләребез саны арта, яңа мәдрәсәләр ачыла, менә хәзер ислам финанслары да үсеш ала. Болар барысы да — Раббыбыз биргән нигъмәтләрдер. Һәм Аллаһы Тәгалә «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятендә безгә болай ди:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ

> **«Раббыгыз: «Әгәр** [иман китереп, изге гамәлләр кылып, Минем сезне дошманнарыгыздан коткару нигъмәтемә] **шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә** [нигъмәтләрне тагын да] **арттырачакмын», —** диде**.**
>
> «Ибраһим», 14:7

Шуңа күрә Раббыбыз биргән чиксез нигъмәтләр өчен рәхмәтле булып, киләчәктә дә динебез, кардәшләребез, илебез үсеше өчен тырышыйк.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илһам хәзрәт Сабанчин,*

*Диния нәзарәтенең шәригать бүлеге хезмәткәре*

*24 нче май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Расүлгә итагать – Аллаһыны ярату

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык мактаулар галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә. Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән сөекле расүлебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез барып ирешсен.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Кеше шундый итеп яратылган: безнең күңелебез яхшылыкка, матурлыкка, байлыкка, дәрәҗәгә, яхшы мөнәсәбәткә омтыла. Адәм баласы үзенә яхшылык эшли, ярдәм итә, бүләк бирә торган кешеләрне, матур сүз белән искә алучыларны ярата. Төптән уйласак, без, мөселманнар, бездә булган бөтен байлыкның, нигъмәтнең, сәламәтлекнең, шатлыкның, якыннарыбызның — боларның барысының да Раббыбыз Аллаһының бүләге икәнлеген аңлыйбыз. Ә Аңа шөкерләребезне, ратуыбызны ничек белгертергә соң? Җавап итеп Хак Тәгалә Коръәндә болай ди:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ

«[Расүлем] **Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шул вакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Димәк, Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтен башкару Раббыбызга чын сөю белән шөкер итүебезне күрсәтү булып тора.

Янә Раббыбыз сөекле Пәйгамбәребез турында болай ди:

مَا ضَلَّ صَاحِبُكُمْ وَمَا غَوَىٰ ﴿٢﴾ وَمَا يَنطِقُ عَنِ الْهَوَىٰ ﴿٣﴾ إِنْ هُوَ إِلَّا وَحْيٌ يُوحَىٰ

**«Иптәшегез** [булган Расүлем хак] **юлдан язмады һәм ялганга да ышанмады. Ул үзе теләгәнне сөйләми. Ул аңа** [Аллаһы Тәгалә тарафыннын Җәбраил [галәйһиссәлам] **аркылы] күңеленә салынган вәхидән башка берни дә түгел».**

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:2–4

وَمَن يُشَاقِقِ الرَّسُولَ مِن بَعْدِ مَا تَبَيَّنَ لَهُ الْهُدَىٰ وَيَتَّبِعْ غَيْرَ سَبِيلِ الْمُؤْمِنِينَ نُوَلِّهِ مَا تَوَلَّىٰ وَنُصْلِهِ جَهَنَّمَ ۖ وَسَاءَتْ مَصِيرًا

**«Кем дә кем, туры юл аңа ап-ачык белдерелгәннән соң, Расүлгә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) каршы килсә һәм мөэминнәрнеке булмаган юлдан китсә, Без аны үзе борылган** [начар] **нәрсәгә юнәлтәчәкбез** [һәм сайлап алган ялгыш юлда берүзен калдырачакбыз]**,** [Ахирәттә исә] **аны җәһәннәмгә кертәчәкбез. Барасы урын буларак ул нинди яман!»**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:115

Бу аятьләрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышының һәрбер мизгеле, әйткән һәрбер сүзе, эшләгән һәрбер гамәле Раббыбызга якынайта торган, Аллаһы ярата торган эшләр икәне күренә. Ә моның киресен эшләү, Аллаһы сакласын, бик бәхетсезләр юлы.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә: «Әгәр мине үзегездән, әти-әниегездән, балаларыгыздан һәм башкалардан күбрәк яратмасагыз, берегезнең дә иманы тулы булмас», — дип әйткән. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ошбу сүзләрендә күренгәнчә, без аның артыннан ияреpгә генә түгел, ә чын йөрәктән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искиткеч олы ярату белән яратырга тиешбез. Бу динебезнең нигезе. Бу олы вазифабызны башкара алабызмы, юкмы — моннан ахирәттәге тормышыбыз хәл ителә. Ләкин йөрәккә бит әмер биреп булмый, ничек итеп күңелебездә Нәбиуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата сөю хисен арттырырга? Әлбәттә, аның тормыш юлын өйрәнеп, аның холкы турында фикерләп.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا

«**Сезнең өчен** [бигрәк тә] **Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм** [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] **Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының расүлендә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) күркәм үрнәк бар».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21

الَّذِينَ يَتَّبِعُونَ الرَّسُولَ النَّبِيَّ الْأُمِّيَّ الَّذِي يَجِدُونَهُ مَكْتُوبًا عِندَهُمْ فِي التَّوْرَاةِ وَالْإِنجِيلِ يَأْمُرُهُم بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَاهُمْ عَنِ الْمُنكَرِ وَيُحِلُّ لَهُمُ الطَّيِّبَاتِ وَيُحَرِّمُ عَلَيْهِمُ الْخَبَائِثَ وَيَضَعُ عَنْهُمْ إِصْرَهُمْ وَالْأَغْلَالَ الَّتِي كَانَتْ عَلَيْهِمْ ۚ فَالَّذِينَ آمَنُوا بِهِ وَعَزَّرُوهُ وَنَصَرُوهُ وَاتَّبَعُوا النُّورَ الَّذِي أُنزِلَ مَعَهُ ۙ أُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

«**Ул кешеләр яннарындагы Тәүрат һәм Инҗилдә** [сыйфатлары] **язылган Расүлгә,** [укый-яза белмәгән, ләкин илаһи тәгълимгә өйрәтелгән Расүлем исемле] **өмми Нәбигә иярәләр. Ул аларны** [иман һәм гыйбадәтләр кебек] **яхшылыкка өнди,** [көферлек һәм гөнаһлар кебек] **начарлыклардан тыя, пакь нәрсәләрне** [Аллаһы исеме белән чалынган хайваннарны һәм нәҗес булмаган бөтен ризыкны] **аларга хәләл итә,** [кан, үләксә һәм риба кебек матди һәм рухи] **кабахәт нәрсәләрне исә аларга харам кыла, авыр йөкләрен һәм моңарчы өсләрендә** [муеннарына салынган] **булган богауларны** [авыр җаваплылыкларны] **алардан ала. Аңа иман китергән кешеләр аны олылаplar, ** [дәгъватын ирештерү юлында] **аңа ярдәм итәрләр һәм аның белән бергә иңдерелгән нурга ияреләр. Әнә шулар — уңышка ирешүчеләр** [булыр]».

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:157

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Һәрбер пәйгамбәрнең аерым бер кабул була торган догасы бар. Алар барысы да ул доганы бу дөньяда кылганнар, ә мин бу мөмкинлекне, өммәтемә шәфәгать кылыр өчен, Кыямәт көненә калдырдым. Аллаһы теләге белән шәфәгатем ширектән сакланганнар өчен булачак»[1].

لَقَدْ جَاءَكُمْ رَسُولٌ مِّنْ أَنفُسِكُمْ عَزِيزٌ عَلَيْهِ مَا عَنِتُّمْ حَرِيصٌ عَلَيْكُم
بِالْمُؤْمِنِينَ رَءُوفٌ رَّحِيمٌ

«**Ий кешеләр! Сезгә** [фәрештәләрдән һәм җеннәрдән түгел, аңлап ияреүегез җиңел булсын дип] **үз арагыздан** [сезнең кебек бер кеше булган] **бер Расүл (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) килде. Сезнең газаплануыгыз аңа авырга килә, ул сезнең** [иманлы булуыгыз һәм бөтен

[1] Имам әл-Бохари җыентыгыннан.

эшләрегезнең җайга салынуы] **өчен тырыша һәм мөэминнәргә карата бик мәрхәмәтле, рәхимле».**

«Әт-Тәүбә», 9:128

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булыр алдыннан «өммәтем, өммәтем» дип кайгырган, Кыямәт көнендә дә «өммәтем, өммәтем» дигән сүзләр белән кубарылачак. Бу аятьләр һәм хәдисләрдән күренә ки, Хәбибебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз чиратында безне, Аллаһының гөнаһлы колларын, үзеннән көчлерәк яраткан, гомеренең иң авыр вакытларында да өммәтен кайгырткан.

Пәйгамбәребезгә итагать хакында Раббыбыз янә болай дигән:

وَمَن يُطِعِ اللَّهَ وَالرَّسُولَ فَأُولَٰئِكَ مَعَ الَّذِينَ أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِم مِّنَ النَّبِيِّينَ وَالصِّدِّيقِينَ وَالشُّهَدَاءِ وَالصَّالِحِينَ ۚ وَحَسُنَ أُولَٰئِكَ رَفِيقًا

**«Кем дә кем Аллаһыга һәм Расүлгә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) итагать итсә, әнә шулар – Аллаһы нигъмәтләндергән пәйгамбәрләр, тугрылар, шәһитләр һәм** [игелек кылган] **изгеләр белән бергә. Иптәш буларак алар нинди яхшы!»**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:69

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер бәдәви килеп, болай дип сораган:

— Ий Аллаһының расүле! Кыямәт көне кайчан?

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм моңа каршы сорау биргән:

— Ә син Кыямәт көненә нәрсә әзерләдең?

Бәдәви җавап итеп:

— Аллаһыны һәм Аның расүлен салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ратуымны, — дигән.

Шуннан соң Пәйгамбәребез болай дип әйткән:

— Кеше бу дөньяда кемне ярата, ахирәттә шуның белән бергә булачак.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сәүбән радыяллаһу ганһе исемле сәхабәсенең кайгылы йөзен күреп, сораган: «Сәүбән, сиңа нәрсә булды?» Күңелен сагыш чолгап алган сәхабә җавап итеп: «Мин ахирәт турында уйланам. Әле бу дөньяда мин аз вакытка синнән аерылып торуга түзә алмыйм. Сине бераз гына да күрмичә торсам, йөрәгем кайгыра һәм сине бик сагына башлыйм. Мәңгелек тормышта син җәннәтнең иң югары дәрәҗәләрендә, ә без, Раббыбыз насыйп итсә, түбән дәрәҗәсендә булачакбыз. Шулвакыт синнән аерылуга ничек түзәрмен?» — ди.

Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа болай дип әйткән: «Сиңа шатлыклы хәбәр: кеше бу дөньяда кемне яратса, Ахирәттә шуның белән бергә булачак».

Аллаһы илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу җавабына сәхабәләр бик каты шатланганнар, чөнки алар Расүлуллаһны үз җаннарыннан да катырак сөйгәннәр.

Расүл Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем минем сөннәтемне тергезә, шул йөз шәһит савабын алачак», — дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә каршында югары дәрәҗәләргә ирешүнең берләнбер юлы — ихластан Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне сөеп, гамәлләребездә, сөйләшүебездә һәм бигрәк тә холкыбызда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кебек булырга тырышу. Хәдистә Мөхәмммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, мин холыкны, әхлакны иң югары, иң күркәм дәрәҗәләргә күтәрү өчен җибәрелдем», — дип әйткән.

Тагын бер мөһим нәрсәне искә төшерик, җәмәгать. Беребез дә Мөхәммәд пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күрмәде, ишетмәде. Кайдан без аның күркәмлеге, олуглыгы, матурлыгы, дәрәҗәсе хакында белдек, кайдан Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата ярату, хөрмәт хисе уянды? Җавабын беләбез. Галимнәребез сәбәпле. Хәдистә: «Галимнәр — пәйгамбәрләрнең варислары», — дип әйтелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән гыйлемне һәм әхлакны сәхабәләр,

сәхабәләрдән — табигыйннар, табигыйннардан — тәбге-табигыйннар һәм шул тәртип белән бүгенге көнгә кадәр галимнәр кабул итеп алганнар һәм безгә аңлаталар. Раббыбыз Аллаһы Үзенең ризалыгын Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иярү, Пәйгамбәребезгә карата мәхәббәткә урнаштырды, ә Пәйгамбәребез турында гыйлемне саклаучылар, Сөннәткә чын ияручеләр алар — галимнәр. Дин галимнәрен ярату — Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ярату. Әлхәмдүлилләһ, җөмһүриятебезне Раббыбыз галимнәр белән зурлады, мәдрәсәләр, дини белем бирү йортлары белән бизәде. Раббыбыз шушы галимнәребезгә, остазларыбызга, укытучыларыбызга, хак динне өйрәнүче шәкертләребезгә карата күңелләребезгә чын хөрмәт, ихтирам, мәхәббәт салып, кулыбыз, телебез, малыбыз белән аларга динебезне үстерергә ихлас ярдәм күрсәтүчеләрдән булырга насыйп итсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәмис хәзрәт Фасахов,*

*Алексеевск районы Урта Тигәнәле авылы имам-хатыйбы*

*31 нче май вәгазе,*

*зөлкагъдә аенының 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Гаиләдә дини һәм милли тәрбия

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Безгә иксез-чиксез нигъмәтләр биреп, бер генә мизгелгә дә Үз рәхмәтеннән ташламаучы, ата-анабызга караганда да ныграк яратучы Аллаһы Раббыбызга дан вә мактаулар булсын. Барча галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, калебләребезнең табибы һәм нуры булып торучы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Кешелек җәмгыятенең иң мөһим һәм иң беренче нигезе булып гаилә тора. Гаиләләр никадәр төзек булса, җәмгыятьтә дә Аллаһы хөкемнәрен үтәү шулкадәр көчле һәм ныклы булачак. Ул гаиләләр тирә-якка яхшылыкны гына таратачак һәм аларга һичкайчан яманлык үтеп керә алмаячак. Мондый гаиләләрдән җәмгыятькә төзекләндерүчеләр генә чыгачак. Алар арасында һәркемгә үрнәк булырлык балалар, игелекле хатын, күркәм тәрбия бирүче ана һәм башка төзекләндерүчеләр булачак.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнар җәмгыятендә һәрвакыт туганлык хөкем сөрсен һәм аларның тормышларын килешү, эчкерсезлек һәм үзара аңлашу тулыландырып торсын өчен бөтен көчен куйган.

Гаиләдәге бөтен уңыш бер-береңне аңлау, гафу итә белү һәм үзара мәрхәмәтле булудан килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән (мәгънәви тәрҗемә): «Мәрхәмәт кылучыларга Аллаһы Тәгалә

дә мәрхәмәт кылыр. Шулай булгач, җирдә булганнарга мәрхәмәт кылыгыз, Аллаһы да сезгә мәрхәмәт кылыр».

Туганнар! Күңел бушлыгын, эч пошу, хәсрәтләнү, тынгысызлыкны бетерә торган бердәнбер юаныч, таяныч — Ислам динебездер. Динебезне белү, өйрәнү, гыйлем алу, халкыбызның күркәм гореф-гадәтләрен, буыннан-буынга тапшырылган дини тәрбия өлгеләрен саклап, балаларыбызга, оныкларыбызга җиткерү — бүгенге көндә гаиләнең төп бурычы булып тора. Әмма гаиләдә ата-ана үзе дә динне белмәсә, әби белән бабайда да гыйлем бик сай булса — бала-оныкларыбызны кем тәрбияләр?! Бүгенге көндә күп кенә мәчетләребез каршында оештырылган дини укулар, мәдрәсәләребез бу нисбәттә балаларыбыз өчен зур ярдәм булып тора. Анда әби-бабайларга да, әти-әниләргә дә, яшүсмер һәм сабыйларыбызга да дин асылын, милли тәрбия бирү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Ризаэддин Фәхреддин әйтүе буенча, дини гыйлем алу Ислам динебездә беренчел нигезләрдән булып тора.

Дин кардәшләрем! Бала тирә-якны танып белүгә иң башлап гаиләдә өйрәнә. Гаилә аша урамга, олы дөньяга чыга. «Оясында ничек, очканда шулай» дигән мәкалебез дә шуннан тугандыр, мөгаен. Ә гаилә тәрбиясенең төп йөге ана җилкәсенә төшә. Төрле яшьтәге һәм дәрәҗәдәге кешеләрдән: «Синең өчен бу дөньяда иң якын кеше кем?» — дип сорасаң, меңләгән җаваплар арасыннан: «Әниемнән дә якын кеше юк бу дөньяда», — дигән җавап өстен чыгар, мөгаен. Әниләребез үз газизләренең булган борчу-шатлыкларын үзләренең йодрык хәтле генә йөрәге аша үткәреп, алар өчен борчылып яши...

Бала үскән саен борчулар арта диләр, ләкин ана кешене бу сүзләр куркытмый, киресенчә, ул сабыена көч биреп, аның белән алга атлый.

Агачның җимешләре өлгергән сыман, балалар да буйга җитеп, анадан аерылалар. Ул баласын бер мизгелгә дә онытмый, аның исән-имин, туры юлдан йөрүен үтенеп, һәр көн Аллаһы Тәгаләдән ялварып сорый. Тик ни

кызганыч, күпчелек вакытта әниләрнең изге сүзләре, догалары өйнең бусагасын атлап чыгуга ук онытыла. Чөнки балада дини тәрбия, иман орлыгы тәрбияләп үстерелмәгән. «Иреккә» чыккач, кошчыкның башын төнге клуб, биюләр һәм башка төрле уйлар бал кортлары кебек сырып ала.

Баланы дини итеп тәрбиялик дисәк, иң башлап гаилә берлегенә ирешергә кирәк. Моннан тагын шундый сорау туа: булачак гаиләне кайда тәрбиялиләр соң? Кызганыч, бу сорауга да төгәл генә җавап табуы кыен. Күпчелек очракта яшь гаиләгә үз дөньясын үз тәҗрибәсенә таянып кына башлап җибәрергә туры килә.

Мәшһүр галимебез Риза Фәхреддиннең: «Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас», — дигән сүзләрен һәр ата-ана үз йортында барысына да күренеп торган урынга алтын хәрефләр белән язып куярга тиеш. Тормыш соңлауны гафу итми. Яңадан дини тәрбия биререгә тырышу кузгалып, күздән югалган поездны куа башлауга тиң.

Кардәшләрем, яшәү рәвешенең төп күрсәткече булып гаилә тора. Гаилә бүген халыкка аңлатыла торганча «әти, әни һәм мин» генә түгел, бәлки «әбибабай, әти-әни һәм без — балалар», ягъни ким дигәндә өч буынны эченә алырга тиеш. Шушындый гаиләдә генә шәхес формалаша, бала дөрес дини тәрбия ала ала. Бүген әби-бабай аерым гаилә булып яши. Шулай булгач, нинди тулы гаилә турында сүз алып барырга мөмкин? Без бүген «яшьләр проблемасы» дип еш сөйлибез. Яшьләрнең бер проблемасы да юк. Бөтен проблема зурларда, ягъни урта һәм өлкән буында. Яшьләргә килгәндә исә, алар дөньяның бөтен ләззәтен, шакшысын татыйлар, чөнки аларны без үзебез — ата-ана — шулай итеп тәрбиялибез. Ә дөресрәк итеп әйткәндә, без аларны тәрбияләмибез, матди яктан тәэмин итәбез, ә тәрбия белән шайтан шөгыльләнә. Безнең тәрбия белән шөгыльләнергә вакытыбыз юк, мәчеткә йөрергә вакытыбыз юк, дөнья малы артыннан куабыз. Күбебез бала өстендәге бурычларның берсен генә дә тиешенчә үтәмибез. Ә бит ата-ананың баласы алдында өч бурычы бар: бала тугач та, аңа матур, мәгънәле исем кушу; бала

уңны-сулны аера башлау белән Коръән өйрәтү; бала балигълыкка ирешкәч, аны никахлаштыру.

Бүгенге әби-бабайларның кайсысы гына үзенең баласы өстендәге бурычын үтәде икән? Алар бит кайчандыр әти-әни булганнар. Бүгенге әти-әниләр дә озакламый әби-бабай булырлар. Аларның да мактанырлыклары юк. Бу хәл кайчанга кадәр шулай дәвам итәр?

Кардәшләрем, балалар — ата-ана өчен тормыш юанычы һәм горурлыгы. Шуңа күрә ата-анага үз-үзләренә ышануга, ялган горурлыкка бирелү кирәкми. Алар тәрбиядә теге яки бу ялгышлыкны ясамау өчен һәрвакыт сак, уяу булырга тиеш. Ата кеше балаларына бирә алган иң яхшы нәрсә — яхшы дини белем, Ислам нигезләренә төшендерү, Коръәнне һәм Сөннәт гамәлләрен өйрәтү.

Ир балаларны кыз балалардан яисә киресенчә, кыз балаларны ир балалардан өстен күрергә ярамый. Әмма Ислам кыз балаларга карата игътибарлырак һәм кайгыртучанрак булуның мөһим булуына басым ясый.

Кардәшләрем, балаларны Ислам тәгълиматында тәрбияләү зур әһәмияткә ия. Кече яшьтән үк аларны гамәл-гыйбадәткә өйрәтү мөһим. Җиде яшькә җиткән баласын ата-ана Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу кирәклегенә төшендерергә тиеш.

Кемдер: «Балага дин кирәкме?» — дияргә мөмкин. Әлбәттә! Кешенең күңеленә «дин» дигән орлыкны салу өчен иң кулай вакыт — балачак, чөнки әле бу вакытта балада саф сыйфатлар өстенлек итә. Балигъ булганчы балада Аллаһыга мәхәббәт формалашкан булырга тиеш. Әгәр без кечкенәдән дөрес тәрбия бирә алсак, бала үзенең динсез вакытын хәтерләмәячәк. Дин аның өчен үзе белән бергә дөньяга килгән һәм үлгәнче алып барасы хакыйкать булып торачак, вә инде ул динсез яшәүне күз алдына да китерә алмаячак.

Динсез кеше башы-аягы белән дөнья мәшәкатьләренә чумган, аның күңел күзе тоныкланган, фәрештә сыйфатларын хайвани һәм шайтани сыйфатлар күмеп киткән була. Ул үз тормышында нәрсәнеңдер җитмәвен тоя,

җаны тыныч түгел, бәргәләнә, ул — әйтерсең лә судан яр кырыена чыгарып ташланган балык. Диннең төп бурычы — баланың югары рухи үсешен тәэмин итү. Рухи үсешнең ачкычы булып Аллаһыны тану тора.

Дин кардәшләрем, әгәр балага кечкенәдән: «Минем турында уйлаучы һәм һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торучы, догаларымны ишетүче, кайгыларымны аңлаучы Зат — Аллаһы Тәгалә — бар», — дигән хакыйкатьне аңлата алсак, иң зур тәрбия биргән булырбыз. «Аллаһыны таныган кеше теле белән дә, кулы белән дә, гамәле белән дә башкаларны рәнҗетмәс», — диде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Бала үзенең ана телен, милли гореф-гадәтләрен дә белергә тиеш. Бүген дә әле кайбер тар фикерле дин әһелләре: «Исламда милләт юк, милли үзенчәлекләргә, гореф-гадәтләргә урын юк», — дип акыл саталар. Әмма Раббыбыз Коръәни Кәримнең «Әл-Хуҗурат» сүрәсенең 13 нче аятендә болай ди:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне** [Адәм исемле] **бер ирдән һәм** [Хава исемле] **бер хатыннан яраттык.** [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] **Без сезне** [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] **танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез –** [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннанан сакланган] **бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы –** [һәрнәрсәне] **Белүче,** [һәрнәрсәдән] **Хәбәрдар».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Ягъни Аллаһы Раббыбыз безгә: «Сезнең өчен бер кавемгә әйләнүегез хәерлерәк», — димәде бит. Милли үзенчәлекләребез, милли гореф-гадәтләрне сакламасак, бер-беребезне ничек танырбыз? Милләтләр кирәк булмаса, Аллаһы Тәгалә аларны яратмас, аятьләре белән әһәмиятен дә аңлатмас иде.

Безнең кебек милли азчылыкны, дини азчылыкны да тәшкил итүче халыкка үзебезнең миллилекне саклау аеруча мөһим. Телебезне, гореф-гадәтләребезне оныту динебездән дә ваз кичүгә китерергә мөмкин. Үз заманында Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләре дә: «Өч төрле әйбер, диндә булмаса да, динне саклый, алар: милли тел, милли кием, милли гореф», — дип язган. Әби-бабаларыбыз башка милләтләрдән аерылып тору өчен, яулыкны да үзләренчә бәйләгәннәр, түбәтәйләрен дә салмаганнар, сакалны да үзләренчә йөрткәннәр.

Кадерле дин кардәшләрем! Үз милләтенең үзенчәлекләре, теле, милли киеме белән горурлана белмәгән бала тулы канлы бала була алмый, үзен кимчелекле, түбән сортлы кеше дип саный. Балаларга бәйрәмнәрнең дә кайсы дини, кайсысы милли, ә кайсысы башка халыклардан кергәнлеген аңлатырга кирәк, аларның файдасы, йогынтысы турында уйларга кирәк: алар дини яки милли аңыбызны үстерәме, рухны баетамы?

Яхшыны яманнан, хәләлне харамнан аерып, дини тормыш алып барырлык кеше әзерләү — безнең төп бурычыбыз.

Кардәшләрем, балаларыбыз каршында кылган гамәлләребез дөрес һәм фәкать Аллаһы ризалыгы өчен булса иде, балаларыбызга дини тәрбия биреп, кылган гамәлләребезнең савапларына ирешеп, дөньяда да, ахирәттә дә Раббыбыз ризалыгында булырга насыйп булса иде!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым!

Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әдип хәзрәт Шакиров,*
*Алексеевск районы Югары Татар Майнасы авылы*
*имам-хатыйбы*

*7 нче июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, барлык нигъмәтләр белән безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек бирсә иде!

Бүген Раббыбызның безгә бер бүләге вә нигъмәте булган зөлхиҗҗә ае башланып китте, аның әһәмияте, фазыйләтләре турында искә төшерик. Зөлхиҗҗә аеның атамасы «хаҗ» сүзеннән алынган. Ул мөселманнар өчен изге, Ислам диненең биш баганасының берсе булган хаҗ сәфәре кылына торган ай булуга ишарә итә. Без мөселманнар өчен әлеге ай аерым мәгънәгә ия һәм аңа аерым әһәмият тә бирү кирәк, чөнки ул – һиҗри календарьнең соңгы ае. Ул — тулы бер елга йомгак ясый, яңа елга кергәндә чистарыну, гөнаһлардан арыну, тәүбә кылу, яңа планнар кору ае. Аллаһы Тәгаләнең безгә — адәм балаларына — җибәргән бер рәхмәте, бәрәкәте бу: ел изге хаҗ

кылына, корбан чалына торган зөлхиҗҗә ае белән тәмамлана. Игелек кылыйм дигән кешегә бәрәкәте, әҗер-савабы әйтеп бетергесез күп.

Ислам динендә аерым айлар, мисал өчен, раҗәб, мөхәррам, зөлкагъдә айлары, аннан соң килә торган зөлхиҗҗә ае харам айлардан санала. Бу айларда билне кысыбрак буарга, гыйбадәтләребезне арттырырга, саваплы гамәлләрне күбрәк кылырга кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге** [катгый карарын белдергән] **язуында** [Ләүхелмәхфүздә] **— унике. Шуларның дүртесе — харам** [айлар]**. Бу —** [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән [галәйһимәссәлам] **калган] хак дин.** [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] **Боларда** [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] **үз-үзегезгә золым итмәгез...»**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Мөселманнар исә изге айларда, көннәрдә, кичәләрдә күбрәк вакыт намазда булырга, садака бирергә, Аллаһыны зикер итәргә тырышалар. Шул рәвешле җәннәткә якынаялар, шайтаннан ерагаялар. Нәкъ менә шул рәвешле Аллаһыга омтылган мөселманнар өчен зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне — иң кулай мөмкинлек. Бу хакта Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата». Әгәр дә сәүдәгәргә: «Менә шундый вакыт җитә: 10 көн эчендә сез 1 еллык ризык, товар җыеп куя аласыз», — дисәләр, ул алдан ук бөтен акчасын әзерләп куячак, билгеләнгән

көннәрне, бөтен эшен ташлап, товар җыюга гына багышлаячак. Соңыннан җиңел, рәхәт яшәр өчен шушы 10 көнне кулыннан ычкындырмаячак. Әйдәгез, без дә Аллаһы биргән мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйк. Рухи үсеш юлында киләсе 12 айга җитәрлек күләмдә бәрәкәт, савап җыеп калыйк.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге хәдисен китерә: «Расүлуллаһ галәйһиссәлам зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне хакында: «Изге һәм саваплы гамәлләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан аеруча яратып кабул ителгән бу ун көннән дә хәерлерәк башка көннәр юктыр», — дип әйтте». Кешеләр: «Хәтта Аллаһы Тәгалә юлында тырышлык күрсәтү дәме?» — дип сорадылар. Ул: «Адәм баласы Аллаһы Тәгалә хакына бөтен байлыгын, барлыгын калдырып чыгып китеп, бернәрсәсез кайтып кергән очрактан кала, хәттта Аллаһы юлында тырышлык күрсәтүдән дә хәерлерәк», — дип әйткән».

Әлеге көннәрнең бөеклеген раслау өчен, Коръәнгә күз салыйк. Изге китапта Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَيَالٍ عَشْرٍ

**«**[Зөлхиҗҗәнең башындагы] **Ун төн белән дә** [ант итәмен]**!»**

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:2

Галимнәр әлеге сүрәгә таянып, зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне фазыйләтләрен Рамазан аеның соңгы ун көнлеге белән чагыштыралар. Бу көннәр Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте, рәхмәте белән тулган көннәр. Үзенең хәдисләренең берсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы юлында тоткан бер көн ураза Аллаһы колының йөзен җәһәннәм утыннан җитмеш еллык ераклыкка читләтер», — дип әйткән. Зөлхиҗҗә ае башлану белән, нәфел уразасын тотабыз. Ул 9 көн дәвам итә. 9 нчы көн, Гает алды көне «Гарәфә көне» дип атала. Ул көн дә мөбарәк көннәрдән санала. Һичьюгы Гарәфә көнендә ураза тоту бик күркәм һәм саваплы булыр.

Хаҗ гамәлләре дә шул вакытта үтәлә. Һәр елны дөньяның барлык илләреннән җыелган берничә йөз мең хаҗи Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында дога һәм гыйбадәт кыла. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хаҗның кабул булуын Гарәфә көне белән бәйләгән. Хәдисләрдә кешенең Гарәфә көне ничек узса, ул көнне кылынган гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә ничек кабул итсә, аның хаҗы да шулай кабул булыр, дип килә. Гарәфә көнендә бирелә торган тагын бер зур бүләк — ураза тоту. Әгәр дә без зөлхиҗҗә аеның беренче көненнән 9 нчы көненә кадәр ураза тота алсак, бу тагы да фазыйләтле. Имам Мөслим җыентыгында китерелгән хәдистән күренгәнчә, Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Гарәфә көнендә ураза тоту хакында сораганнар. Ул: «Әлеге көндә ураза тоту үткән елгы һәм киләсе елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», — дип җавап биргән. Димәк, Гарәфә көнендә тотылган бер көн ураза ике еллык гөнаһларны кичерерлек дәрәҗәдә саваплы булып чыга. Әйдәгез, мөселман кардәшләрем, әлеге мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйк. Бу көнне Аллаһы Тәгаләгә тәкъвалыкта, гыйбадәтнең ихласлылыгында ярышыйк.

Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне турында сөйләгәндә тагын бер мәсьәләне читләтеп үтәргә ярамас. Мөселманнар өчен атна саен тырнак кисү һәм чәч-сакал кыскарту сөннәт гамәл санала. Әмма зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлегендә бу гамәлләрне читкә куеп торсак, яхшырак булыр. Аллаһы Тәгаләнең сөекле колларының берсе имам Әбү Хәнифә бу уңайдан болай дигән: «Зөлхиҗҗәнең беренче ун көнендә әлеге сөннәтне калдырып торсагыз хәерлерәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Корбан чалырга җыенган кеше зөлхиҗҗә ае керүгә тырнагын да, чәчен дә кисмәсен», — дигән хәдисе катгый күрсәтмә түгел. Әмма шулай да әлеге гамәлләрне корбан чалынганнан соң гына үтәү мөстәхәб саналыр». Димәк, корбан чалырга ниятләгән кешегә, хаҗиларга охшау йөзеннән, чәч, сакал, мыек кыскартмау, тырнак кисмәү мөстәхәб гамәл саналыр. Әмма бу гамәлне вәҗиб, ягъни мәҗбүри дип санау дөрес түгел. Тырнагын яки чәч-сакалын кискән кеше гөнаһлы булмас, аның корбан чалуының савабы да кимемәс, иншәАллаһ!

Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә кылынырга мөмкин булган иң саваплы гамәл — хаҗ сәфәрендә булу. Аллаһы Тәгалә әлеге изге гамәлне гомердә бер тапкыр булса да кылырга насыйп итсен иде, чөнки хаҗ сәфәренә барган, андагы барлык йолаларны тиешле дәрәҗәдә үтәгән мөселманнарга Аллаһы Тәгалә гаҗәеп дәрәҗәдә әҗер-саваплар әзерли. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Кабул кылынган хаҗның әҗере җәннәт нигъмәтләренә тиңдер», — дигән. Аллаһы Тәгалә адәм балаларының изге юлда булуын, аларның саваплы гамәлләр белән яшәвен хуп күрә. Шуңа күрә Аның рәхмәтенә ирешү өчен хаҗга ният итәргә кирәк. Изге сәфәргә барам, дип ният иткән мөселманга Аллаһы Тәгалә акчасын да, җаен да, яхшы юлдашын да насыйп итә. «Изге ният — ярты гамәл» дигән мәкальне ишеткәнегез бардыр. Хаҗ кылу мөмкинлеге булмаган очракта да, көннәребезне гамәлгыйбадәттә үткәрергә тырышсак иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ

«[Шулай булгач] **Раббың өчен намаз укы һәм** [Аның исеме белән] **корбан чал** [да, корбан итләрен юксылларга тарат]**».**

«Әл-Кәүсәр / Муллык», 108:2

Корбан чалырга теләүчеләр бу изге гамәлне башкарырга алдан ук әзерләнә башлый. Аллаһы Тәгалә мөмкинлеге булган һәр кешегә Корбан чалуны фарыз итә. Бу уңайдан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә каршында иң бөек көннәр булып Корбан бәйрәме һәм әлкарр көннәре тора», — дип әйткән. Әл-Карр көне — зөлхиҗҗә аеның унберенче көне, ул гарәп теленнән сүзен сүзгә тәрҗемә иткән вакытта — «урнашу, булу»ны аңлата, чөнки хаҗ кылучылар бу көнне хаҗ кылуның бар йолаларын да башкарып бетереп (тәваф әл-ифада (Кәгъбә тирәсендә җиде кат әйләнү), корбан чалу), Мина үзәнендә булалар.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең кызы Фатыйма радыяллаһу ганһәгә: «Корбан чалдыр, чөнки корбан канының тамган беренче тамчысы ук гөнаһларның ярлыкануына сәбәп булыр. Кыямәт көнендә исә ул корбан ителгән хайванның мөгезләре, тиресе, әгъзалары, йоны һ. б. мизанга салынып, барча гөнаһлардан да авыррак булыр. Корбан ителгән хайванның һәрбер бөртек йоны өчен 40 мең әҗер-савап язылыр», — дип әйткән. Әбү Сәгыйть әл-Ходри радыяллаһу ганһе исемле сәхабә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Ий Аллаһының илчесе! Бу эштән хасил булган әҗер-саваплар синең йорт әһеленә генә хас рәвештә булырмы, әллә барча мөэмин-мөселманнарга да кагылырмы?» — дип сораган. Пәйгамбәребез: «Өммәтемнән һәркем корбан чалса, ул кешегә бу әҗер-саваплар һәммәсе дә бирелер», — дигән. Корбан итенең өчтән бер өлеше туганнарга, күршеләргә өләшенергә тиеш. Өчтән бер өлеше — мохтаҗларга, калган өлеше гаилә әһелләренә кала.

Шулай итеп, бер зөлхиҗҗә ае өчен генә дә бик күп гыйбадәтләр җыела. Ул — гает намазы, ураза, хаҗ, корбан чалу, садака бирү һәм башка бик күп төрле гамәлләр. Бу — Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән мөмкинлеге һәм бу форсатны кулдан ычкындырмасак иде! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*14 нче июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең саубуллашу хотбәсе һәм соңгы нәсыйхәте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Шушы галәмнәрне юктан бар кылган, һәм шушы галәмнәрне тәрбия кылып торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә йөрәк түрләребездән чыккан хәмед-сәналәребез булса иде. Җир йөзендә яшәгән кешеләрнең иң хөрмәтлесе, шушы галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез барып ирешсә иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бар дөньяда мөселман өммәте зарыгып көтеп алган беренче изге ай Рамазан ае булса, икенчесе, әлбәттә, ул — хаҗ кылына торган, корбан чалына торган зөлхиҗҗә ае. Әлхәмдүлилләһ, бүген без мәчетләребездә җомгага җыелган булсак, хаҗ сәфәренә киткән миллионлаган дин кардәшләребез бүген, зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә, Мәккә шәһәреннән Минага кузгалдылар. Алдагы көннәрен алар анда хаҗ гыйбадәтләрен үтәп, безнең өчен догалар кылып уздырса, без исә монда намазларыбызны укып, бар өммәтебез өчен догалар кылып, Гарәфә көнендә ураза тотып, Гаеттә корбаннар чалдырып, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешергә тырышыйк. Киләсе елларда безгә дә кабул хаҗлар кылырга насыйп булсын, дип теләп торыйк һәм ниятләп, шушы гамәлне башкарырга максат куйыйк.

Барыбыз да хаҗның динебезнең бер баганасы булуын белә. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай диелә:

إِنَّ أَوَّلَ بَيْتٍ وُضِعَ لِلنَّاسِ لَلَّذِي بِبَكَّةَ مُبَارَكًا وَهُدًى لِّلْعَالَمِينَ ﴿٩٦﴾
فِيهِ آيَاتٌ بَيِّنَاتٌ مَّقَامُ إِبْرَاهِيمَ ۖ وَمَن دَخَلَهُ كَانَ آمِنًا ۗ وَلِلَّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ
الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلًا ۚ وَمَن كَفَرَ فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ عَنِ الْعَالَمِينَ

**«Һичшиксез, кешеләр** [гыйбадәт кылсын] **өчен корылган тәүге йорт — мөбарәк һәм** [кыйблалары булу белән] **галәмнәр өчен һидаять булган Мәккәдә** [Кәгъбәдә]**. Анда** [беркемдә дә буталчык тудырмый торган] **ап-ачык аятьләр** [вә галәмәтләр] **һәм Ибраһимның мәкамы бар. Кем дә кем анда керсә,** [курыкканнарыннан] **имин булыр. Юл үтеп аңа** [җитәргә] **көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен** [Әл-Харам мәчете булган] **Бәйткә хаҗ кылырга тиеш. Кем дә кем** [хаҗның фарызлыгын инкяр итеп] **кяфер булса, һичшиксез, Аллаһы —** [һичнинди гыйбадәткә һәм һичкемгә ихтыяҗы булмаган] **бөтен галәмнәрдән бай** [Зат]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:96-97

Кәгъбәтуллаһ — Җир яратылганнан башлап изге урын булып торган. Мөселманнар гына түгел, мөселман өммәтенә кадәр яшәгән бер Аллаһыга ышанган борынгы халыклар, пәйгамбәрләр дә Кәгъбәне зиярәт кылган. Алай гына да түгел, хәтта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кадәр яшәгән Мәккә мөшрикләре дә Кәгъбәнең изге урын булуын белгән. Әмма алар, потларга табынучылар буларак, анда потларын урнаштырып, төрле гөнаһлы йолалар башкара торган була. Бар кешелек дөньясына хак юлны өйрәтүче итеп җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм генә бу куркыныч гадәтләрне туктата һәм безгә хаҗ тәртипләрен, бу изге урыннарга тиешле гыйбадәтләрне өйрәтеп калдыра.

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз тормышында хаҗны фәкать бер тапкыр кылган. Бу вакыйга һиҗри 10 нчы елда була. Аңа кадәр, без беләбез, Мәккә мөшрикләре Пәйгамбәребезне, мөселманнарны

шәһәргә кертми. Әмма һиҗри 10 нчы елга Ислам дине инде бар Гарәбстан ярымутравына тарала, элек бер-берсенә дошман булган кабиләләр, халыклар берләшә; байлар, фәкыйрьләр, ак һәм кара тәнле кешеләр — барысы да бер-берсенә дин кардәше булып китә. Инде бар кешелек тарихын, тормышын үзгәртәчәк Ислам дине бу вакытка ныгый. Шушы чорда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Раббыбыз хаҗ кылырга әмер итә һәм ул бу ниятен сәхабәләренә җиткерә. Бу хаҗ сәфәре тәфсилләп хәдисләрдә тасвирланган. Сәхабәләр хаҗ кагыйдәләрен, тәртипләрен генә түгел, безгә сөекле Пәйгамбәребезнең һәр сүзен, һәр гамәлен, хәтта ул атланып хаҗга барган дөянең кушаматына кадәр тапшырган. Аллаһы Тәгалә аларның барчасыннан разый булсын!

Димәк, зөлкагъдә аеның ахырында, әл-Кәсва атлы дөясенә атланып, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәдән хаҗ кылырга кузгала. Бу вакытка, шулай ук хаҗ кылырга ниятләп, бик күп мөселманнар Мәдинәгә агылган була. Җәбир исемле сәхабә бу хакта болай ди: «Мин алдыма карадым, анда бар җирдә җәяүле һәм атланган кешеләр иде, уңга һәм сулга карадым — шулай ук, артыма борылып карадым — һәм җыелган кешеләрнең ахыры да, чиге да күренми иде». Ягъни Ислам тарихындагы әлеге беренче хаҗны Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә меңләгән мөселман кардәшебез кылган. Аллаһы Тәгалә Расүленә хаҗның бар тәртипләрен өйрәтеп торган, ә мөселман җәмәгате Пәйгамбәребез артыннан тиешле гамәлләрне, сүзләрне кабатлап барган. Тарихтагы иң күркәм, иң камил хаҗ шул рәвешле башкарылган.

Шушы хаҗ сәфәрендә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга хаҗ тәртипләрен генә өйрәтеп калмый. Ул, шушындый зур форсаттан файдаланып, Гарәфәт үзәнлегендә җыелган меңләгән хаҗиларга мөрәҗәгать итә. Тарихка бу хотбә «саубуллашу хотбәсе» дип кереп калган. Сәхабәләр бу хотбәне бик зур игътибар белән тыңлап, башка буыннарга да тапшырган һәм бүген без дә, күпме гасырлар узганнан соң, Пәйгамбәребезнең

бу хотбәсен китаплардан укып белә алабыз. Бүген без бу хотбәне тулысынча китермичә, аннан кайбер дәресләргә генә тукталып китәрбез.

Бу хотбәсен сөйли башлагач, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләрне дикъкать белән тыңларга һәм сүзләрен шушы хаҗга килә алмаган кешеләргә җиткерергә өнди. Моннан без аңларга тиешбез, әйтеләчәк нәсыйхәтләр сәхабәләргә генә яисә борынгы заманнарда яшәгән мөселманнарга гына түгел, ә безгә дә, кешеләр космоска оча башлаган дәвердә яшәүче мөселманнарга да, һәм Кыямәт көне җиткәнче бу дөньяга киләчәк һәр мөселманга да кагыла.

Беренчедән, Расүлуллаһ кеше хакларыннан башлый: «Чынлыкта, сезнең өчен бүгенге көн, бу ай һәм бу шәһәр (ягъни Мәккә) ничек изге булса, сезнең гомерләрегез дә, мал-мөлкәтегез дә шулай изге булырга тиеш», — ди ул. Ягъни берәүнең дә, ул нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен, башка кешенең хакына керергә, хаксызга канын коярга, малын тартып алырга хокукы юк. Һәм без моны һәрвакыт истә тотып, хәтта бик вак тоелган мәсьәләләрдә дә кеше хакына керергә тиеш түгелбез. Мәсәлән, әгәр без кайдадыр чиратка баскан кешеләрне күреп, шунда чиратсыз гына кереп китәбез икән, уйлап карыйк, берьюлы ничә кешенең хакын бозабыз икән. Тормышта мондый вак-төяк тоелган очраклар көн саен булып тора, без үзебезне һәрвакыт тикшереп торырга өйрәнергә тиешбез.

Алга таба Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә әманәт итеп бирелгән әйберне хуҗасына кайтарырга боера. Әманәт ул — кешегә саклап торырга дип вакытлыча бирелгән әйбер. Ул кыйммәтле булырга да, безгә кирәксез, бер иске әйбер булып тоелырга да мөмкин. Әмма мөселман кардәшең нәрсәнедер сиңа әманәткә биргән, ә син риза булып алгансың икән, син аны үз шәхси малыңнан, әйбереңнән дә яхшырак саклап тотып, вакытында кайтарып бирергә тиешсең. Әманәтне үзең өчен кулланырга, игътибарсыз булып бозарга, югалтырга ярамый.

Хотбәдән өченче зур дәрес — ул риба мәсьәләсе. Хөрмәтле дин кардәшләрем, без рибаның, гади генә әйткәндә процентның, Исламда тыелган

булуын беләбез. Бу хакта Коръән аятьләрен дә, хәдисләрне дә китергәнебез бар. Карагыз, саубуллашу хотбәсендә Пәйгамбәребез бу сорауга кабат тукталган, бурычка акча биргәндә йә алганда, биргән яки алган акчагызны гына кайтарыгыз, өстәп акча сорамагыз яки үзегез арттырып кайтармагыз, дигән. Беребез дә бүген 21 нче гасырда рибасыз инде яшәп булмый, дип акланмасын. Өммәтебез тагын миллион ел яшәсә дә, безнең өчен Аллаһының бу хөкеме калачак. Без, мөселманнар, риба гөнаһына кермичә, үзебез өчен хәләл булган юллар табарга, динебез кануннарына туры килгән финанс продуктларны үзебез булдырырга тиешбез. Башкалар моны безгә әзерләп бирмәс.

Киләсе бик зур дәрес ул — хатын-кызларның хакын хаклау. Беребезгә дә сер түгел инде, бар дөньяда диярлек, Ислам хатын-кызларны кыерсыта, хокуксыз итә, дигән ялган һәм ялгыш фикерләр таралган. Без исә монда безнең гаеп юкмы икән, бәлки без башкаларга динебезне дөрес итеп күрсәтә белмибез, ә бәлки тиешенчә хатын-кызларыбызның хакларын үтәп бетерә алмыйбыздыр, дип уйланырга тиеш. Кызганыч, бүгенге көндә балалары белән хатынын тәэмин итмәүче, хөрмәт итмәүче мөселманнар бар. Ә саубуллашу хотбәсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын-кызларның хакларын вә хокукларын саклауда Аллаһының ачуыннан куркыгыз!» — ди. Расүлебез хатын-кызларыбызны матди яктан җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итеп, алар белән итагатьле, мәрхәмәтле булырга васыять итә.

Алга таба сөекле Пәйгамбәребез: «Мин сезгә Коръәни Кәримне һәм Сөннәтемне калдырдым. Алар буенча яшәсәгез — беркайчан да туры юлдан адашмассыз», — ди. Һәм бу янә Коръәнне укырга өйрәнүнең, аның мәгънәләрен, шулай ук хәдисләрне, сираны, галимнәребезнең хезмәтләрен өйрәнүнең әһәмиятен ассызыклый. Намаз укырга өйрәнүдә генә тукталып калмасак иде, бүгенге көндә булган күпсанлы мөмкинлекләрне, китапларны, остазларыбызның дәресләрен файдаланыйк, балаларыбызга беренче чиратта яхшы дини белем бирергә тырышыйк.

Саубуллашу хотбәсеннән тагын күп файда, нәсыйхәтләр алырга мөмкин. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә болай дип мөрәҗәгать иткән: «Ий кешеләр! Дөреслектә, миннән соң пәйгамбәр булмас һәм сездән соң башка өммәт булмас. Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз, биш вакыт намаз укыгыз, фарыз уразаны тотыгыз, малыгыздан зәкят чыгарыгыз, Бәйтүллаһка хаҗ кылыгыз, хакимнәрегезгә буйсыныгыз, һәм сез җәннәткә керерсез».

Хотбәсенең ахырында Пәйгамбәребез: «Иртәгә (ягъни Кыямәт көнендә) сездән минем хакта сораячаклар. Сез ни дип әйтерсез?» — дип сорый. Сәхабәләр: «Син безгә динне җиткердең, үз вазифаңны үтәдең, безгә киңәшләр вә нәсыйхәтләр бирдең, дип шәһадәт китерербез», — дип җавап кайтаралар. Мондый җаваптан соң Расүлуллаһ: «Йә Раббым, моңа шаһит булчы!» – дип өч тапкыр кабатлый.

Шушы бөек хаҗның Гарәфә көнендә икенде намазыннан соң Аллаһы Тәгалә «Әл-Маидә» сүрәсенең өченче аятен иңдерә. Бу озын аятьтә мондый сүзләр бар:

ٱلْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ ٱلْإِسْلَامَ دِينًا ۚ

> **«Бүген сезнең өчен динегезне камил иттем,** [Мәккәне алуны насыйп итү белән динегезне бөтен ялган диннәрдән өстен кылып] **сезгә нигъмәтемне тәмамладым һәм сезнең өчен, дин буларак, Исламнан канәгатьмен ...»**

«Әл-Маидә / Табын», 5:3

Бу аятьне ишеткәч, Гомәр радыяллаһу ганһе үксеп елап җибәрә. Ул сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең фани тормышы ахырына якынлашканын сизә. Йә Раббым, безгә дә Расүлебезне тиешле дәрәҗәдә яратып, ул әйтеп калдырган нәсыйхәтләрне үтәп яшәргә насыйп кыл.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, иртәгә Гарәфә көне, мөмкинлеге булган һәр мөселман ураза тотсын. Аның фазыйләтләре хакында узган җомгада сөйләшкән идек. Шулай ук иртәгә иртәнге намаздан башлап, Пәйгамбәребезнең күркәм сөннәтен үтәп, һәр фарыз намаздан соң тәкбир сүзләре әйтелер. Аны мәчетләрдә җәмәгать намазларыннан соң да, өйләрегездә үзегез генә укысагыз да, сәфәрдә булсагыз да әйтергә кирәк. Иратлар кычкырып, хатын-кызлар үзләре ишетерлек итеп кенә: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләһә илләллаһ вәллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә лилләһил хәмд», — дип кабатлыйбыз. Тәкбир әйтү быел иртәгәдән, 15 нче июньнән башлап, 19 нчы июньнең икенде намазына кадәр дәвам итәчәк, иншәАллаһ.

Раббыбыз Аллаһы барчаларыбызның хата-кимчелекләрен гафу итеп, гыйбадәтләрен кабул кылсын, киләчәктә безгә кабул хаҗлар насыйп итсен. Быел хаҗ сәфәрендә булган барча дин кардәшләребезнең гыйбадәтләрен кабул итеп, исән-имин әйләнеп кайтырга насыйп итсен. Барчабызга файдалы гыйлемнәр алып, сөекле Пәйгамбәребезнең сөннәте буенча яшәп, шәһадәт кәлимәләре белән бакыйлыкка күчәргә һәм Расүлебез шәфәгатенә ирешергә насыйп булсын!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» нәшрият бүлеге*

## Корбан гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

### خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

### الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلاَمُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لآَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّـهَ اِنَّ اللَّـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّـهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاَيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّـهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّـهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّـهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّـهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّـهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّـهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللّٰهِ، اِنَّ اللّٰهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللّٰهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

# Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Аллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр. Ләә иләәhә илләллааhү, вәллааhү әкбәр, Аллаhү әкбәр вә лилләhил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүhү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиhил-җәләәли вәлҗәмәәл.

Аллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр. Ләә иләәhә илләллааhү, вәллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр, вә лилләhил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнhи ҙәәтиhил-гукуулү вәл-әфhәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиhир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр. Ләә иләәhә илләллааhү, вәллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр вә лилләhил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәhүл-мүэминиинә бишшүhүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии hәәҙиhил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-тауәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр. Ләә иләәhә илләллааhү, вәллааhү әкбәр, Аллааhү әкбәр вә лилләhил-хәмд. Нәхмәдүллааhәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләhү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләhү вәлиййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирhү тәкбиираа. Вә әшhәдү әлләә иләәhә илләллааhү вәхдәhүү ләә шәриикә ләh. Вә әшhәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүhүү вә расүүлүhү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә’и би әмрилләәhил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааhү тәгааләә вә сәлләмә галәйhи вә галәә әәлиhи вә әсхәәбиhил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүhән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм hәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хауәәссый вәл-гауәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруhү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү hәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә

иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгә-тин вәд-даʼнү вәл-мәгзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәәʼү вәл-гарҗәәәʼү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтиҫәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү га-ләйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәш-риикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңҙур нәфсүм-мәә каддәмәт лигаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәәʼири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфирүһү вә нүʼминү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә эшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәл-ләзиинә әәмәнү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Саллии вә сәллим гәләйһи вә гәләә җәмиигиль-әнбийәә’и вәл-мүрсә-лиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мукаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадыыйн. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү’миниинә вәл-мү’минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә’и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә’әр-раашидиинә вәл-үмәрааа’әл-мәдый-нәл-ләзиинә кадау билхәккы вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаҙәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ’мүрү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи ҙил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхшәәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиҙукум ләгәлләкүм тәҙәккәрүүн. Үҙкүрул-лааһәл-галиййәл-гаҙыымәл-хәййәл-кайййүм, йәҙкүрүкүм вәшкүрүүһү йәзидкүм, вәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм вә ләҙикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әгләә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгҙаму вә әтәмму вә әкбәр.

## Корбан гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының Заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлы-гына һәм олуглыгына барлык мәхлүкъләр дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, пәйгамбәребез Мөхәммәд – Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) – җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм Олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә корбанны: «Корбан чал!» – дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан

итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек – җиде кешедән, сарык вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар – Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир тәшрикъне Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһыга сыенам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм).

Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыенабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд Аның колы һәм хак Расүле булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки: Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәр салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәр салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә Мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син – догаларны кабул итүче, бәрәкәт индерүче,

дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне зикер итү – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәләләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*16 нчы июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Безнең күңелләребезне иман нуры белән нурландырган Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз һәм шөкраналарыбыз булса иде. Бөтен пәйгамбәрләрнең имамы булган, безгә бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырга өйрәткән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Ерак һәм якын җирләрдән килеп, шушы изге Корбан бәйрәме көнендә Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәр өчен мәчетебезгә җыелдык.

Хөрмәтле мөселманнар! Елга бер мәртәбә була торган бөек бәйрәмебез — изге Корбан гаете — барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен. Мөкаддәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтенә барчабызга да ирешергә насыйп булсын!

Аллаһы Раббыбыз һәркайсыбыздан догага мохтаҗ, бу дөньядан иманлы булып киткән барлык мәрхүмнәребезнең һәм мәрхүмәләребезнең гөнаһларын, хата-кимчелекләрен гафу итеп, рухларын шат кылса иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аның кушканнарын үтәп, тыйган гамәләреннән тыелып яшәү — кешенең төп вазифасы булып тора. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә кешене бу

дөньяга нәкъ менә шуның өчен җибәрде дә. Һәрбер мөселман үзенең Раббысына омтылырга, Аны искә алырга, һәрбер гамәлне Аның ризалыгы өчен кылырга тиеш, чөнки ул бары тик Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аркасында яши. Кайвакыт кеше үз Раббысын онытып, хаталар, гөнаһлы гамәлләр кыла, үзен һәлакәт чокырына ташлый, калебен каралта. Шушы гөнаһлардан, хатакимчелекләрдән пакьлану, Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларының берсе — хаҗ гыйбадәте. Бөтен ислам галимнәренең уртак фикере буенча, хаҗ гыйбадәте һәрбер хәлле мөселман өчен фарыз (тиешле) гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

**«Юл үтеп аңа** [җитәргә] **көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен** [Әл-Харам мәчете булган] **Бәйткә хаҗ кылырга тиеш».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер мөбарәк хәдисендә: «Әгәр берәү хаҗ кылып, бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр», — дигән[1].

Бүген, ягъни зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, хаҗилар хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлап, ихлас күңелләре белән Кәгъбәтуллага юнәлеп, тәлбия, ягъни: «Ләббәйкәллаһүммә ләббәйк. Ләббәйкә ләә шәриикә ләкә, ләббәйк! Иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлк, ләә шәриикә ләк!» («Йә Аллаһы, менә мин Синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк! Барча мактау Сиңа гына, барлык нигъмәт һәм хөкем Синең кулыңда гына! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк!») — дип әйтәләр.

Газиз дин кардәшләрем! Төрле илләрдә яшәүче ничәшәр йөз миллион мөселманнар кебек, без дә бүген изге Корбан гаетенә шатланып, тәһарәтгоселләр алып, пакь, матур киемнәр киеп, хушбуйлар сөртеп, тәкбирләр әйтеп, Аллаһы йортына, ягъни мәчеткә җыелдык.

1 Әл-Бохари, Мөслим, ән-Нәсаи.

«Корбан» сүзе нәрсәне аңлата соң? «Корбан» гарәпчәдән «якынаю», «якын булу» дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә Гает намазын укып, Аллаһы ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып сафланабыз һәм Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю, хөрмәт, бер-береңә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык һәм үпкә хисләре бетә.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһының рәхмәтенә якынайта торган изге Корбан бәйрәме тирән мәгънәгә ия. Гарәпчә бу бәйрәм «Гыйд әл-әдха» дип атала. «Әдха» сүзе корбан чалу дигәнне аңлата. Мәгълүм булганча, корбан чалу йоласы безгә Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнән калган. Корбан бәйрәме тарихын искә төшерик.

Ибраһим пәйгамбәрнең галәйһиссәлам озак еллар баласы булмаган. Аллаһының рәхмәте белән Ибраһим галәйһиссәламнең улы туган, аңа Исмәгыйль исеме кушылган. Берничә еллар үткәч, Ибраһим галәйһиссәлам Мәккә шәһәрендә булган вакытта, төшләр күрә башлаган. Ул төшләрдә Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә улы Исмәгыйльне корбан чалырга куша…

Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә кешенең канын түгүче түгел, ул бары Ибраһим пәйгамбәрне шул рәвешчә сынады, Исмәгыйль галәйһиссәлам үзе дә сынатмады. Әтисе аны корбан итеп чалырга алып барганда, шайтан котыртып: «Сине атаң кунакка алып бармый бит, ул сине чалырга алып бара бит», — дигән. Исмәгыйльнең иманы бик нык була. Ул бу хәлдә: «Әгәр бу Аллаһының әмере булса, без аны үтиячәкбез», — дип әйтеп, шайтанны ташлар атып куган. Ибраһим пәйгамбәр белән улы Исмәгыйль галәйһиссәлам арасында булган сөйләшүне Аллаһы Тәгалә Коръәндә китерә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَىٰ ۚ قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«Ул аның белән бергә** [эшләрендә] **тырышлык куюга** [мөмкинлек биргән унөч яшьләргә] **җиткәч** [атасы аңа]**: «Ий улым! Һичшиксез, мин** [берничә төн рәттән] **төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара», — диде. Ул: «Ий әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне** [һич уйлап тормыйча] **үтә. ИншәАллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», — диде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:102

Уйлап карагыз әле, җәмәгать, Исмәгыйль галәйһиссәламгә ул вакытта нибары 13 яшь кенә була. Ибраһим галәйһиссәлам улын бугазлыйм дип торган заманда Җәбраил фәрештә килеп, аны бугазлатмаган, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, улы урынына бер куй китереп, шуны корбан итеп чалырга кушкан. Җәбраил фәрештә шушы куйны китергәч: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр», — дип әйткән. Ибраһим галәйһиссәлам тәкбирне ишеткәч: «Ләә иләһә илләллааһу вәллаһу әкбәр», — дип әйткән һәм аннан соң Исмәгыйль галәйһиссәлам: «Аллаһу әкбәр вә лилләәһил хәмд», — дип өстәгән. Бүгенге көндә мөселманнар бу сүзләрне Гарәфә көнендә һәм Корбан гаете көннәрендә һәрбер фарыз намаздан соң кабатлыйлар.

Ибраһим галәйһиссәлам улын азат кылган һәм Җәбраил фәрештә алып килгән куйны чалган. Шул вакыттан бирле бу йола безгә бәйрәм булып кала.

Без корбан чалганда шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Коръәндә Үзе әйтә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә».**

«Әл-Хаҗ», 22:37

Тәкъва булган, Аллаһыны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһының ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Изге Коръәндә болай дип әйтелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَابْتَغُوا إِلَيْهِ الْوَسِيلَةَ وَجَاهِدُوا فِي سَبِيلِهِ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз** [һәм Аның колларын җәфаламагыз]**,** [әмерләрен тоту, тыюларыннан качу һәм Аның дусларын сөю кебек гамәлләр белән] **Аңа якынаю юлларын эзләгез һәм Аның юлында җиһад кылыгыз, бәлки, сез** [дөньяда һәм Ахирәттә бәхеткә һәм] **уңышка ирешә алырсыз».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:35

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әгәр без Аллаһы газабыннан котылырга һәм Аның рәхмәтенә ирешергә, бәхетле булырга телибез икән, алдагы аятьтә әйтелгәнчә, Ислам юлында тырышырга, ягъни Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәр көнне гөнаһлардан сакланып, Аллаһыга шөкрана кылып, күбрәк игелекле гамәлләр эшләп яшәргә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкарә» сүрәсенең 29–30 нчы аятьләрендә болай дип әйткән:

هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا ثُمَّ اسْتَوَىٰ إِلَى السَّمَاءِ فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ ۚ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ ﴿٢٩﴾ وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي

جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ ۖ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ ﴿٣٠﴾

**«Ул** [Аллаһы] **Җирдә булганнарның бөтенесен сезнең** [мәнфәгатегез] **өчен яратты, шуннан** [Үзенең Кодрәте белән] **күкне** [яратуга күчте]**. Һәм аны** [бернинди кимчелексез] **җиде** [кат] **күк рәвешенә китерде. Ул —** [һәрнәрсәне] **Белүче. Менә Раббың фәрештәләргә: «Һичшиксез, Мин җирдә хәлифә** [итеп Адәмне [галәйһиссәлам] **яратачакмын!» — дип әйткәч, алар** [каршы төшү максаты белән түгел, ә хикмәтен белер өчен]**: «Әллә җирдә бозыклык кылучыны һәм кан коючыны яратачаксыңмы? Без бит һәрвакыт Сиңа мактау белән тәсбих әйтәбез,** [Затыңның бөтен кимчелекләрдән пакь булуын танып] **олылыйбыз», — диделәр. Ул: «Һичшиксез, Мин сез белмәгәннәрне беләм!» — диде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:29-30

Шул рәвешле, Аллаһы Раббыбыз Адәм балаларын күркәм сурәттә яратып, акыл биреп, барлык мәхлуклардан өстен кылган. Аллаһы Тәгалә җир өстендә һәм астында булган байлыкларны, нигъмәтләрне, диңгезләрдәге хисапсыз күп балыкларны, төрле мәхлукларны безгә буйсынучы итеп яраткан. Безгә, адәм балаларына, бернинди мәхлукка бирелмәгән хәлифә дәрәҗәсе бирелгән. Инде Аллаһы Раббыбыз безне шундый олуг нигъмәтләр белән бүләкләгәннән соң, безгә зур гына вазифалар, бурычлар йөкләгән. Коръәни Кәримдә «Әт-Тәхрим» сүрәсенең 6 нчы аятендә адәмнәр өстендәге олуг вазифаларның кайберләре искә алына. Шул вазифаларны үтәмәүчеләр каты газапка дучар булачаклары турында белдерелә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ

**«Ий иман китерүчеләр!** [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] **Үзүзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз,** [башка утларның ягулыгы утын булса] **аның ягулыгы** [кяфер] **кешеләр һәм** [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] **ташлар».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:6

Шулай итеп, Аллаһы Раббыбыз бу аять белән безгә үзебезне һәм гаиләбезне дөнья, ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар эшләрдән тыеп, җәһәннәм газабыннан сакларга куша. Өстебездә булган зур бурычларыбыз хакында Аллаһының расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Әй, бәндә, синең өстеңдә Раббыңның хакы, нәфесең һәм әгъзаларыңның хакы бар һәм гаиләңнең хакы бар, һәрбер хак иясенә хакларын бир, вазифаңны үтә».

Беренче бурыч – Аллаһы Тәгалә каршында булган бурыч, ягъни дөньяны, бөтен галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһыны тану, биргән барлык нигъмәтләренә шөкрана кылып, һәрвакыт, һәр җирдә Аллаһы хозурына барып, хисап бирәчәгебезне истә тоту.

Икенче бурыч – кешенең үзе хакындагы бурыч, ягъни Аллаһы биргән тән сәламәтлеген саклау. Авыру булса — дәвалану. Күп кенә тән авырулары дөрес тукланмаудан килә. Бүгенге көндә без чамадан тыш күп ашыйбыз һәм эчәбез, ашказаннарыбызга ял бирмибез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ашказанын өчкә бүләргә кушкан: бер өлеше ризык өчен, бер өлеше — су, бер өлеше һава өчен[1]. Аллаһы Раббыбыз бу хакта Үзенең китабында да әйткән:

كُلُواْ وَاشْرَبُواْ وَلاَ تُسْرِفُواْ

**«Ашагыз, эчегез, әмма** [хәләлне харам итеп, яки харамга катышып, яки туклык чиген узып] **исраф итмәгез».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:31

1 Тирмизи.

Күп ашау кунак сыйлаганда һәм сәхәр вакытында гына дөрес санала. Без һәрвакыт дөрес туклануга игътибар итәргә тиеш, чөнки 50 процент авырулар ризыктагы матдәләр аша килә. Мәсәлән, шәригатьчә бугазланмаган хайваннарның итләрендә зарарлы матдәләр күп була. Ризыкны яхшы ният һәм фикер белән әзерләү шулай ук мөһим булып тора. Сырхау килгәнче сәламәтлегебезнең кадерен белик.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Пакьлек (чисталык) — иманның яртысы», — дигән[1]. Шуңа күрә суны еш куллanырга, һәрвакыт тәһарәтле килеш йөрергә тырышырга кирәк. Су — яшәү чыганагы: суны никадәр күбрәк куллансак, шулкадәр сәламәтлегебез артачак. Ашаганчы һәм ашаганнан соң бер чеметем тоз куллану — авыруларның профилактикасы булып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәннең сәламәтлеген саклау өчен, корсакка ятып йокламаска, уң якка ятарга киңәш иткән.

Адәм баласының үзе хакындагы икенче бурычы — акылны гыйлем белән баету. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Белем алу — һәрбер мөселман өчен фарыз (тиешле)», — дигән[2].

Мөселман кеше дөньяви гыйлемме, дин гыйлемеме — икесен дә тигез күреп, өйрәнергә бурычлы, чөнки дөньяви гыйлем белән дини гыйлем үзара бәйләнгән рәвештә бер-берсен тулыландыра.

Адәм баласының үзе хакында өченче бурычы — күңелен, җанын тәрбияләп, начар сыйфатлардан арындырып, күркәм сыйфатлар белән бизәп, бөтен кешеләр белән дус, тату, тыныч торырга һәм игелекле гамәлләр кылырга тырышу. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә сезне тышкы кыяфәтегез һәм матди быйлыгыгыз буенча бәяләмәс. Ул сезнең күңелләрегезгә (калебләрегезгә) һәм сез кылган гамәлләрегезгә карый», — дип әйткән[3].

1 Мөслим, Тирмизи.

2 Ибне Мәҗә.

3 Табәрани.

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Белегез, кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт булыр, әгәр ул авыру булса, бөтен тән авыру булыр. Белегез ки, ул ит кисәге — калебтер»[1].

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, динебез калебкә зур әһәмият биреп, аңа игътибарлы булырга боера. Һәр мөселман үз калебенә хуҗа булырга тиеш. Калебләребезне сафландыру — һәрбер мөселманның изге бурычы. Калебләрне өч төргә бүлергә мөмкин.

Беренчесе — иман белән нурланган калебләр. Алар — Аллаһыга һәм Аның Расүленә бәйләнгән, Ислам шәригатенә буйсынган бәхетле калебләр.

Икенчесе — ширек һәм көферлек белән каралган калебләр. Алар — яшәү мәгънәсен аңламаган, бары тик матди, дөньяви ләззәтләргә бирелгән бәхетсез калебләр.

Өченчесе — гөнаһ белән пычранган калебләр. Аларга ия булган кешеләр беренче карашка иман нигезләрен кабул иткән булып күренсәләр дә, намаз, ураза кебек гыйбадәтләрне вакытында үтәмиләр яисә бөтенләй башкармыйлар. Шундый калебләр исерткеч эчемлекләр куллану, отышлы уеннар уйнау, риба, ялган кебек гөнаһларга баткан.

Иң гүзәл калебләр — иман, Ислам нуры белән нурланган, күркәм гамәлләр белән бизәлгән һәм һәртөрле гөнаһтан сакланган сөенечле калебләр. Аларга ия булучылар ике дөньяда да бәхеткә ирешәчәкләр. Шуңа күрә мөселман һәрвакыт һәм һәр урында калебне каралта торган гамәлләрдән ерак торырга тырыша. Киресенчә булса, ул үзен олы куркынычка илтә. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөэмин бер гөнаһ эшләгән вакытта аның калебендә бер кара тап барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итеп, бу гөнаһтан ваз кичсә, аның калебе пакьләнә. Әгәр ул тәүбә итмәсә һәм гөнаһлы гамәлне кылуны дәвам итсә, аның калебендә кара таплар саны арта һәм калебе каралана», — дигән[2].

---

[1] Әл-Бохари, Мөслим.

[2] Ибне Мәҗә.

Түбәндәге аятьләрне истән чыгармыйк:

قَدْ أَفْلَحَ مَن زَكَّاهَا ۞ وَقَدْ خَابَ مَن دَسَّاهَا

«[Нәфесен яхшы якка үзгәртеп, гөнаһлардан ерак тотып] **Аны арындырган кеше уңышка ирешкән. Аны** [фасикълык баткаклыгы эчендә] **яшергән кеше зарар күргән».**

«Әш-Шәмс / Кояш», 91:9–10

أَلاَ بِذِكْرِ اللّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**«Күңелләр Аллаһыны зикер итү белән тынычланмыймы?»**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:28

يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ ﴿٨٨﴾ إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

«[Хәерле юлда сарыф ителсә дә] **Бер малның да,** [шәфәгать итә алырлык дәрәҗәдә булган] **улларның да** [беркемгә] **файда бирмәгән көнне. Мәгәр** [көферлек һәм монафикълык кебек хасталыклардан тәмам котылып] **керсез күңел белән Аллаһыга килүче булмаса гына».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:88-89

Мөхтәрәм мөселманнар! Шуны һәрвакыт истә тотыйк: күп санлы изге гамәлләрне ихлассызлык белән үтәүгә караганда, аз санлы гамәлләрне ихласлык белән кылу күпкә яхшырак. Бу турыда бөек ислам шагыйре, фикер иясе Җәләлетдин Руми әсәреннән бер кыйсса сөйләп үтәсем килә.

Кешеләр үзләренең җитәкчеләренә аларның зур җирлекләр белән идарә итә белүләре өчен генә түгел, ә халыкка эчкерсез мөнәсәбәтләре, күркәмлекләре өчен илтифат иткән заманда, еш кына Багдадка (башкала) бүләк яки яхшы сүз белән җитәкчегә үзләренең хөрмәтләрен һәм рәхмәтләрен тапшырырга бара торган булганнар. Бервакыт бер фәкыйрь дә үзеннән бүләк тапшырырга уйлаган, ләкин озак уйланулар һәм эзләнүләр нәтиҗәсендә үзендә бернинди

кыйммәтле нәрсә дә тапмаган. Инде өметен өзеп, ул үзенең бердәнбер байлыгы булган кырые кителгән, ләкин әле кулланып була торган иске чүлмәкне искә төшергән. Ул аңа үзенең коесыннан су тутырган һәм юлга чыккан.

Багдад юлында берәү очрап, фәкыйрьдән кая һәм ни өчен юл тотуы турында сораган. Җавапны ишеткәч, сораучы: «Тыңла әле, хакимдә күпме телисең, шулкадәр су бар, хәтта синең коеңдагы су да аныкы!» — дигән. Фәкыйрь аптырап калган, ләкин элеккеге ниятен саклап: «Мин гади кеше, кыйммәтле бүләгем булмаса да, җаным аңа мәхәббәт белән тулы, һәм мин аңа бу суны булса да бүләк итү теләге белән янам», — дип җавап биргән.

Ул юлын дәвам иткән һәм исән-имин килеш солтан сараена килеп җиткән, үзенең бүләген тапшырган, аны хөрмәт һәм кунакчыллык белән каршы алганнар. Өйгә кайтырга җыена башлагач, солтан да аның бүләгенә каршы бүләк бирергә теләгән: «Синең бүләгеңнең тышкы яктан нинди булуы мөһим түгел, — дип әйткән хаким, — аның чүлмәген алтын белән тутырыгыз!» — дигән. Ягъни бу кыйссадан күрәбез: гамәлең бик кечкенә булырга да мөмкин, әмма ул ихлас күңелдән, чын-чынлап Аллаһы ризалыгы өчен булсын. Мондый гамәл-гыйбадәт әҗерсез калмас.

Адәм балаларының өченче бурычы — гаиләсе, ата-анасы, туган-тумачалары хакындагы вазифасы. Гаилә турында шуны әйтергә кирәк: бөек динебез аның һәрбер әгъзасына күп кенә вазифалар йөкләгән. Гаиләнең һәр әгъзасы үз вазифаларын төгәл үтәсә, шул вакытта гаилә нык булачак, шуңа күрә шул вазифаларны белү генә җитми, аларны җиренә җиткереп үтәргә дә кирәк. Ул бурычлар түбәндәгеләр:

— гаилә башлыгы буларак, ир кеше бәхетен һәм сөенечен үз гаиләсендә генә эзләргә, башка гаилә әгъзаларыннан җитдирәк һәм төплерәк булырга, үз гаиләсен кирәк нәрсәләр белән тәэмин итәргә һәм Ислам буенча яшәргә бөтен шартлар тудырырга тиеш;

— хатын-кыз иң беренче чиратта иренә карата булган вазифаларны үтәргә тырышырга, аны үз мәхәббәте, йомшаклыгы, игътибарлылыгы белән

бүләкләргә һәм, әлбәттә, гаиләнең намусын һәм шәрәфен сакларга тиеш;

— ир һәм хатын якты чырайлы, тәмле телле булырга, бер-берсен аңлап, хөрмәт итеп яшәргә, гаилә серләрен тышка чыгармаска, ниндидер аңлашылмаучанлык, каршылык килеп чыкса, бер-берсенә юл куярга, кирелек күрсәтмәскә тиеш;

— ата-ана үз балалары өчен күркәм үрнәк булырга, аларның матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш. Алар һәрбер балага гадел булырга, аларны начар дуслардан, харам гамәлләрдән сакларга, яхшы белем һәм тәрбия бирергә, киләчәктә үзләренә күркәм холыклы тормыш иптәшләрен табарга ярдәм итәргә тиеш;

— балалар, үз чиратында, әти-әниләрен хөрмәт итәргә, тел белән дә, гамәлләре белән дә рәнҗетмәскә һәм үлемнәреннән соң да онытмыйча, алар өчен дога кылып торырга тиешләр.

Алда әйтелгән кагыйдәләр буенча яшәгән гаилә, иншәАллаһ, нык, сәламәт һәм бәхетле булачак. Туган-кардәшләребез — безнең өчен ата-аналарыбыздан соң иң якын кешеләр, шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булырга тырышыйк. Алар хакында Пәйгамбәребез: «Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен», — дип әйткән[1].

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазем ахырында сезне бер риваять белән таныштырып үтәсем килә. Бөек галим Җүнәйд әл-Багдадига 7 яшь булганда, абыйсы Сәрий әс-Сәкати аны үзе белән хаҗ гыйбадәтен кылырга алып барган. Харам мәчете («Изге мәчет» дигән сүз) эчендә, ягъни Кәгъбәтулла янында, төрле мәсьәләләр буенча сөйләшүләр барган, шуларның берсе шөкрана кылу турында булган. Анда катнашкан һәр шәех бу турыда үз белем-тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сәрий әс-Сәкати Җүнәйдкә борылып, аңа шөкрана турында үз фикерен белдертергә кушкан. Бераз уйлагач, 7 яшьлек Җүнәйд түбәндәге гаҗәеп матур җавап биргән: «Шөкрана кылу ул — Аллаһы

1 Әл-Бохари, Мөслим.

Тәгалә каршында гөнаһлы булмау, Аның нигъмәтләрен файдаланып, шулар белән гөнаһ кылмау», — дигән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу җаваптан күренгәнчә, Аллаһыга шөкрана кылу, Аңа рәхмәт әйтү ул — намаз уку, ураза тоту, Коръән уку кебек гыйбадәтләр белән генә чикләнми. Без Аллаһы Раббыбыз биргән әгъзаларыбыз белән дә гөнаһ эшләмәскә тиеш. Күзебезне — харам булган нәрсәләрдән, телебезне гайбәттән, ялганнан, яла ягудан, буш сүзләрдән саклыйк. Телләребез белән күбрәк Аллаһыны искә алыйк, файдалы, дөрес сүзләр сөйлик. Карыныбызны харам ризыклардан, кулларыбызны харам гамәлләрдән, аякларыбызны Аллаһының ачуын китерә торган җирләргә барудан саклыйк. Хәдис-шәрифтә болай диелгән: «Файдасыз эшләрдән качу — яхшы мөселманның билгесе»[1].

Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас шөкрана кылучылардан булырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт томышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Казанның «Апанай» мәчете имам-хатыйбы*

[1] Тирмизи.

*21 нче июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Гөнаһларыңа аклану эзләмә

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, шул галәмнәргә рәхмәтен һәрдаим ирештереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә шөкерләребез һәм зикерләребез булсын! Һәм дә Аның Расүле, иң күркәм әхлак мисалы булган остазыбыз Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу тормышта без еш кына Раббыбыз безгә биргән зур мөмкинлекләрне файдаланмыйча, гафләткә бирелеп яшибез. Без мөмкин булганча күбрәк гыйбадәт кылырга, тәүбә итәргә тырышмыйбыз. Кызганыч, моның урынына без еш кына төрледән-төрле аклanулар табып, үзүзебезне алдап, гади генә әйткәндә иллюзияләр дөньясында яши башлыйбыз. Ә иллюзия ул — чынбарлыкны бозып, үзгәртеп күз алдына китерү. Бүген шул хакта фикер йөртербез.

Әүвәл адәм баласына хас булган ике төр гөнаһны искә аласым килә. Шундый гөнаһлар бар, кеше аларны бик еш кыла, хәтта аның нәфесе бу гөнаһларга өйрәнеп бетә, алардан башка әйтерсең яши алмый башлый, аларны кылуын ул сизми дә диярлек.

Икенче төр гөнаһлар ул — без инде көрәшеп җиңә алган, арына алган гөнаһларыбыз. Аеруча намаз укучы, Рамазан айларында ураза тотучы кешеләргә Аллаһы Тәгалә гөнаһларыннан арынырга көч-куәт бирә, аларны пакьли. Һәм кайберләребез менә шушы инде котылган, җиңә алган гөнаһларына кире әйләнеп кайта. Аларны кылганда ул үзен аклый башлый,

тәүбә итә алырмын әле, дип уйлый. Әмма шул рәвешле без үзебезне алдыйбыз. Гөнаһ кылганда үзеңне алдарга, акларга кирәкми! Кыямәт көнендә моның нәтиҗәсе бик куркыныч булачак.

Шуңа күрә, хөрмәтле дин кардәшләрем, гөнаһлардан һәм бигрәк тә инде кайчандыр калдыра алган, җиңә алган гөнаһларыбыздан сакланыйк, кире шул упкынга кайтмыйк. Ә бу бик җиңел килеп чыга. Бигрәк тә без берәр аклану тапсак. Мәсәлән, кайберләребезнең диннән ерак, бик ерак булган танышлары булырга мөмкин. Кемдер шундый танышы белән бергә ниндидер дөрес булмаган, гөнаһлы гамәл кылып йөрергә мөмкин. Бу бик кечкенә гамәл була ала. Һәм шушы мөселманның нияте нинди: менә хәзер мин шушы дустым белән янәшә, без якынаербыз, дустым миңа яхшырак карый башлар да, соңрак дингә дә килер, намаз кыла башлар. Әмма бу алдану! Шушы мөселманнан шайтаннар егыла-егыла көлә. Әлеге гөнаһ кылып йөрүче танышларыбыз да ни дип уйлый: «Ярый инде без, ә сез бу мөселманга карагыз, ул шушы гөнаһлардан ерак була ала торып, шушында безнең арада гөнаһ кылып йөри, безнең белән вакытын гафләттә үткәрә». Алар да чынлыкта шул мөселманнан көләләр. Мондый алдану, үз-үзеңне алдаудан сакланыйк! Ул аеруча куркыныч, бу очракта сине шайтан алдамый, юк, син үзең үзеңне алдыйсың. Син шундый гөнаһлы юл аша нәрсәгәдер ирешә алачакмын, дип алданасың.

Ә чынлыкта бар бәрәкәт, нигъмәтләр фәкать хәләл нәрсәләрдә генә, Раббыбыз Аллаһының рәхмәтендә генә яшеренгән. Аллаһы Тәгалә бәрәкәт бирмәсә, тәүлегенә 24 сәгать, елына 365 көн эшләп тә, ач-ялангач йөрер идек. Дөньядагы бөтен шайтаннар белән дуслашып чыксаң да, бу сиңа ярдәм итә алмаячак.

Адәм баласына хас икенче төр алдану вакыт узу белән барлыкка килергә мөмкин. Менә кеше берничә ел дәвамында намазлар кылды да, ә кайвакыт хәтта бер ай да җитә, һәм үзен дөньядагы иң чиста, хәтта Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә иң якын кеше итеп хис итә башлады. Ул үзен

гөнаһсыз, дин буенча яшәүче дип масайды. Менә шушында иң куркыныч гөнаһларның берсе яшеренә, ул да булса — тәкәбберлек. Тәкәбберлек ул еш кына изгелек артында качып торырга мөмкин. Башка гөнаһлардан арынуга караганда, монсыннан арыну күпкә авыррак шул. Монда гыйлем дә ярдәм итмәскә мөмкин, гыйлем ияләренә дә тәкәбберлек хас була ала. Монда фәкать Аллаһы Тәгалә ярдәм итә ала. Ә Ул тәкәбберлекне ничек дәвалый? Мәсәлән, вакытында авырулар бирә, кайгылар бирә һәм кешене туктата, айнытып җибәрә. Әмма бу бик авыр сынау. Аллаһының «башка сугуы» бик авыр ул. Моңа барып җитмәвебез, үзебезне башкалардан яхшырак, өстен күрмәвебез хәерлерәк.

Бу гөнаһны ничек танып алырга була? Тәкәббер кеше әйләнә-тирәдәгеләргә бәя биреп, хөкем чыгарып йөри башлый: фәлән дөрес эшләми, бу фәлән хата кыла. Ул барысын төзәтә башлый. Әмма хөкем чыгару вазифасы кешегә бирелгән булса, Ахирәт көне дә кирәк булмас иде. Аның башка атамасы да бар — Хисап көне. Нәкъ Хисап көнендә Аллаһы Раббыбыз колларына Үзе хөкем чыгарачак, бәя бирәчәк.

Кемдер үзен Аллаһы каршында иң чиста кеше дип уйлап йөри икән, беренче чиратта тәүбә итсен, ә икенчедән — Аллаһы Тәгалә Хисап көнендә аны иң чиста, гөнаһсыз кешеләрнең берсе дип атасын, дип ялварсын. Раббысы шулай атаса, әлбәттә, бу кешенең үзенә дә, башкаларга да бик рәхәт сүз булыр. Ә атамаса? Моның урынына бар кеше алдында бөтен гөнаһларын ачып күрсәтеп, оятка калдырса? Хисап көнендә ничек котылырбыз? Без бу дөньяда хата-кимчелекләребезне яшереп йөри алабыз, әмма Хисап көнендә яшерә алмабыз, әлхәмдүлилләһ. Бар кимчелекләребез Аллаһы Раббыбыз каршында булыр һәм теләсә, Ул аларны башкаларга да ачып күрсәтер. Яисә Үз рәхмәте белән, безне оятка калдырмас, гөнаһларыбызны үзебезгә генә күрсәтеп, башкаларга күренмәс итәр, гәрчә һәркайсыбыз бу дөньяда яшәгән барлык кешеләр алдында басып торачак. Без һәркайсыбыз бу хөкемне үтәчәкбез. Беребез дә шикләнмәсен, шайтан беребезгә дә икеләнү, шик салмасын.

Раббыбыз Аллаһы шушы мизгелдә һәм һәрвакыт һәркайсыбызның ризыгын биреп, йөрәк тибешен, ми эшчәнлеген, эчке һәр әгъзабызның эшчәнлеген тикшереп тора. Бу Аның өчен кыенмы? Әлбәттә юк! Аның өчен бернәрсә дә кыен түгел. Һәрберебезне хөкем итү дә кыен түгел.

Раббыбыз бу хакта бик күп аятьләр иңдергән. Мәсәлән, «Әл-Инфитар» сүрәсе болай башлана:

إِذَا السَّمَاءُ انفَطَرَتْ ﴿١﴾ وَإِذَا الْكَوَاكِبُ انتَثَرَتْ ﴿٢﴾ وَإِذَا الْبِحَارُ فُجِّرَتْ
﴿٣﴾ وَإِذَا الْقُبُورُ بُعْثِرَتْ ﴿٤﴾ عَلِمَتْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ وَأَخَّرَتْ ﴿٥﴾

**«Күк ярылгач. Йолдызлар коелгач. Диңгезләр ташыгач. Каберләр асты өскә әйләнгәч. Һәрбер җан киләчәккә ни әзерләгәнен һәм үзеннән соң калдырган һәрнәрсәне** [үзенәниләр казандырачагын һәм башына нинди бәлаләр китерәчәген] **беләчәк».**

«Әл-Инфитар / Ярылу», 82:1–5

Һәм һәркайсыбыз Раббысы хозурына ничек кайтасын уйласын. Без тәүбә кылып, ихлас, пакь калебләр белән булырбызмы, әллә тәкәббер, барысын да хөкем итүчеләр булып кайтырбызмы?

Яшәвебезнең төп максаты ул – гөнаһлардан пакьләнеп, Аллаһы Тәгаләгә мөмкин кадәр күбрәк гыйбадәт кылып яшәү һәм шәһадәт кәлимәсе белән бу дөньядан китү. Әмма ахирәткә күчкәндә бар кеше дә бу сүзләр белән китми шул. Бар дөньяга танылган кешеләрнең тормышлары хакында укып карагыз, алар бакыйлыкка ничек киткән? Кыямәт көнендә дә кешеләр соңгы сүзләре белән кубарылачак.

Үз-үзебезне алдаудан, гөнаһларыбызны аклаудан сакланыйк. Мондый алдануларның саны чиксез, дөньяда күпме кеше булса, һәркем үз-үзен үзенчә алдап, аклап яши ала. Чынбарлыкны ачык күреп, үзебезгә карата гадел булыйк, Кыямәт көненә әзерләнеп яшик. Дөреслектә, һәрберебезнең шәхси кыямәте үлеменнән соң башланачак.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин,*

*Казанның «Котдус» мәчете имам-хатыйбы*

*28 нче июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Сүзеңдә тору – иманнан

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз, хәмед-сәналәребез безне юктан бар кылып, күңелләребезгә иман нуры салган галәмнәрнең Раббысы, тәрбиячесе Аллаһы Тәгаләгә булса иде.

Галәмнәргә рәхмәт итеп иңдерелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Хөрмәтле мөэмин-мөселман кардәшләрем! Раббыбыз Аллаһы Тәгалә «Ибраһим» сүрәсенең 27 нче аятендә болай дип сөендерә:

يُثَبِّتُ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا بِالْقَوْلِ الثَّابِتِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ ۖ وَيُضِلُّ اللَّهُ الظَّالِمِينَ ۚ وَيَفْعَلُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ

**«Аллаһы иман китергән кешеләрне дөнья тормышында да, Ахирәттә дә көчле** [тәүхид кәлимәсе булган] **сүз белән** [Ислам динендә] **ныгыта. Әмма Аллаһы залимнәрне юлдан яздыра. Аллаһы теләгәнен кыла».**

«Ибраһим», 14:27

Әйе, тормышыбызда адашмыйча, тынычлык табар өчен, Ул безне иман белән куәтләде; тормышыбызны тәртипкә салыр өчен, безгә Үзенең шәригатен бирде; тормышыбызда үзара мөнәсәбәтләребез нык булсын дип, безне күркәм булган әдәп-әхлаклар белән зиннәтләде.

Безне Үзенең сүзе белән ныгытырга вәгъдә итүе аша безне дә сөйләшкәндә сүзләребезгә ялган кертмичә сөйләшергә һәм әйткән сүзләребезгә, биргән вәгъдәләребезгә тугры булырга өндәп, Раббыбыз «Әл-Әхзәб» сүрәсендә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلًا سَدِيدًا ۞ يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَمَن يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм туры сүз сөйләгез. Шулвакыт Ул** [Раббыгыз] **сезнең гамәлләрегезне төзәтер һәм гөнаһларыгызны кичерер. Кем дә кем** [әмер һәм тыюларын үтәү мәсьәләсендә] **Аллаһыга һәм Аның расүленә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) итагать итсә, һичшиксез, ул** [үлчәп булмаслык дәрәҗәдә] **зур котылуга ирешкән».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:70–71

Бу мөрәҗәгатен Аллаһы Тәгалә безгә, иман әһелләренә юнәлтте. Беренче чиратта, тәкъва булырга әмер итүе белән Ул иманыбызга тагын бер кат игътибар итәргә өнди.

Икенчедән, Ул Үзе дә сүзләрендә һәм вәгъдәләрендә һәрвакыт тугры булганына күрә, безгә дә сүзләребезгә ялган кертмичә, вәгъдәләребезгә тугры булырга әмер итә.

Һәм өченчедән, тәкъвалыкка нигезләнгән тугры сүз һәм вәгъдәләребез өчен бүләк буларак тормышларыбызны җайга салып, гөнаһларыбызны гафу итеп, безгә олы уңышлар, бөек җиңүләр бирүен вәгъдә итә.

Кардәшләрем! Әйе, без бүген әлегә диннән ерак булган җәмгыятьтә яшибез, һәм, кызганыч, күрәсең, без үз-үзебезне шуның белән акларга тырышып, кайчак үзебезнең әйткән сүзләребезгә, биргән вәгъдәләребезгә салкынрак карыйбыз, яисә сөйләшкәндә дөресен әйтеп бетермичә, яшереп калабыз да, шуның белән үзебезне ниндидер уңай нәтиҗәләргә ирешә алырбыз, дип

уйлыйбыз. Әмма Аллаһы Тәгалә «Мөэминнәр» сүрәсенең башында ук иман әһелләрен, аларның кайда яшәүләренә һәм нинди генә халәттә булуларына карамастан, аларны «әманәтләрен һәм сүзләрен үтәүчеләр» дип тасвирлый. Әле генә китерелгән «Әл-Әхзәб» сүрәсендәге аятьтә дә: «Һәм туры сүз сөйләгез», — дип әмер итә. Нәкъ менә туры, ялгансыз сүз сөйләвебез сәбәпле, безнең тормышыбыздагы гамәлләребезне тәртипкә китерергә, әле шуның өстенә гөнаһларыбызны гафу итәргә вәгъдә бирә.

Шулай ук дөрес сүз сөйләвебезне Аллаһыга һәм Аның илчесенә итагать итүгә тиңләп, безгә эшләребездә олы уңышлар вәгъдә итә. Шуны онытырга ярамый: Аллаһы Тәгалә беркайчан да биргән вәгъдәсен бозмый.

Моңа дәлил буларак Ислам тарихында билгеле булган бер мисал китерәсем килә. Бүген иң күп мөселманнар яшәгән ил ул — Индонезия. Анда якынча 240 миллион мөселман кешесе яши. Ислам Индонезия утрауларына сигезенче гасырда Гарәбстан ярымутравы сәүдәгәрләре аша килеп керә дә, аларның сәүдә эшендә күрсәткән гаделлек һәм сүзләренә тугры калулары сәбәпле, тиз арада халык арасында киң тарала. Белгәнебезчә, безнең җирлегебездә дә Ислам гадел сәүдәгәрләр аша таралып, безгә хәтле килеп җитә алды, әлхәмдүлилләһ. Моның сәбәбе булып аларның сәүдә эшләрендә күрсәткән гаделлекләре һәм әйткән сүзләрен, биргән вәгъдәләрен үтәүдә күрсәткән тугрылыклары тора. Бу эшне үти алган сәүдәгәрләр арабызда күптән юк инде, әмма Кыямәт көнендә алар Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән җәннәткә пәйгамбәрләр белән керәчәкләрен күз алдыбызга китерсәк, аларның нинди «зур котылуга ирешкән» булуларын аңлыйбыз.

Сүз биреп тә вәгъдәдә тормауның нинди нәтиҗәләргә китерүе хакында Раббыбыз Аллаһы Тәгалә «Саф» сүрәсенең 2–3 аятьләрендә кисәтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لِمَ تَقُولُونَ مَا لَا تَفْعَلُونَ ۞ كَبُرَ مَقْتًا عِندَ اللَّهِ أَن تَقُولُوا مَا لَا تَفْعَلُونَ

> **«Ий иман китерүчеләр! Ни өчен эшләмәячәк нәрсәләрегезне сөйлисез? Эшләмәячәк нәрсәләрне сөйләвегезгә Аллаһының ачуы** [һәм нәфрәте] **бик зур».**
>
> «Әс-Сафф / Саф», 61:2–3

Кардәшләрем, уйлап карыйк әле! Сүзләребезгә һәм вәгъдәләребезгә тугры булмыйча, Аллаһының ачуына һәм дә нәфрәтенә дучар булуыбыз белән без нинди олы уңышларга ирешә алырбыз икән соң? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт әйткән сүзенә тугры булган, һәр сүзен тормышка ашырган, һәм шул сәбәпле һәр эшенең ахыры һәрвакытта да уңышлы булып тәмамлана торган булган. Хәдисләренең берсендә расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне кисәтеп әйтә: «Кемдә шушы дүрт сыйфат булса, ул монафикъ булыр. Әмма кемгә ул сыйфатларның берсе генә булса да хас булса, аннан (ул сыйфаттан) арынганчыга кадәр ул кеше икейөзлелек сыйфатына ия була:

— сүз сөйләсә, ялганлый;

— вәгъдә бирсә, вәгъдәсендә тормый;

— аңа әманәт бирелсә, әманәтенә хыянәт кыла;

— килешү төзесә, аны үтәми».

Без шуны аңлыйк, кардәшләрем: биргән вәгъдәләребезне бозганда безнең йөрәкләребезгә икейөзлелек сыйфаты керә. Шул сәбәпле, безнең эшләребездә беркайчан бернинди бәрәкәт тә, хәер дә булмаячак, ул булырга да мөмкин түгел.

Ә эшләребездә уңышка ирешергә телибез икән, без бөтен Кодрәт Анда гына булган Аллаһыга таянып эш итәргә өйрәнергә тиеш. Белгәнебезчә, Йосыф галәйһиссәлам зинданда булганда, аның янәшәсендә торган егеткә үзенең үтенечен белдергәндә: «Мине хуҗаң янында телгә ал», — дип әйтә, әмма бу үтенеченә өстәп: «ИншәАллаһ» (Аллаһы боерса)», — дип әйтергә оныта, һәм шул сәбәпле Йосыф галәйһиссәлам гомеренең әле тагын берничә елын тоткынлыкта, әсирлектә үткәрергә мәҗбүр була.

Шуңа күрә безгә Раббыбыз Аллаһы Тәгалә «Әл-Кәһф» сүрәсенең 23–24 нче аятьләрендә ачыктан-ачык итеп әйтә:

وَلَا تَقُولَنَّ لِشَيْءٍ إِنِّي فَاعِلٌ ذَٰلِكَ غَدًا ۞ إِلَّا أَن يَشَاءَ اللَّهُ ۚ وَاذْكُر رَّبَّكَ إِذَا نَسِيتَ وَقُلْ عَسَىٰ أَن يَهْدِيَنِ رَبِّي لِأَقْرَبَ مِنْ هَٰذَا رَشَدًا

**«Берни турында да: «Мин моны иртәгә эшләячәкмен», – дип әйтмә. «Мәгәр Аллаһы теләсә** [генә эшләрмен]» [дип әйт]. **Әмма** [моны] **оныткан чагыңда Раббыңны исеңә төшер һәм: «Бәлки, Раббым мине моннан да якынрак булган бер юлга ирештерер», – дип әйт».**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:23–24

Аллаһыга шөкер, әйе, без бүген сөйләшкәндә гарәпчә итеп «иншәАллаһ» дип тә, татарчага тәрҗемә итеп: «Аллаһы боерса», «Аллаһы теләсә», — дип тә әйтәбез. Әмма әле без «Аллаһы боерса моны эшлим», — дип әйтүебез белән Аллаһы Раббыбызны вәгъдәбезне үтәвебезнең гаранты буларак игълан иткәнебезне, кызганыч, аңлап бетермибез. Менә күз алдыбызга китерик, без: «Аллаһы боерса, мин моны эшлим», — дип әйттек тә, ялкаулыгыбыз белән әйткән сүзебезне үтәми калдырдык, ди. Читтән караганда эшебезнең үтәлмәве безнең сәбәпле түгел, ә Аллаһының теләмәве белән шулай булган кебек булып чыга. Без сүзебезне әйтеп, аны үтәмичә, Аллаһы Раббыбызның вәгъдә иткән ачуына дучар булабыз түгелме соң? Без мөэмин-мөселман дигән бөек исемнең дәрәҗәсен төшерәбез түгелме соң? Бәлки, безгә «иншәаллаһ», «Аллаһы боерса», «Аллаһы теләсә» дигән сүзләргә җитдирәк карарга кирәктер? Кардәшләрем, әгәр дә нәрсәнедер үти алмаячагыбызны сизәбез икән, үз өстебезгә андый йөкне алмыйк! Сүзебез авызыбыздан чыкканчы, аның хуҗасы — без, ә сүз авызыбыздан чыгуы белән, ул безнең хуҗабызга әверелгәнен онытмыйк, җәмәгать!

Без, мөселманнар буларак, сүзебезне әйтергә дип авызыбызны ачканда, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әмеренә

буйсынып: «Ләә иләәһә иллә Аллаһ» сүзен әйтеп, шул сүзгә тугры булып яшик, шулай эш иткәндә генә Раббыбыз Аллаһы Тәгалә безне бу фани тормышыбызда да, мәңгелек Ахирәттә дә шул ук «ләә иләәһә иллә Аллаһ» сүзе белән ныгытыр, иншәАллаһ.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илнур хәзрәт Фәйзуллин,*

*Теләче районының Олы Мәтәскә авылы имам-хатыйбы*

*5 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Мөхәррам ае

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактау-данлау Аллаһы Тәгаләгә булсын! Без Аңа шөкрана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Үзебезнең начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаһы Тәгаләдә сыену эзлибез! Аллаһы туры юлга күндерсә, берәү дә адаштыра алмас, Аллаһы адаштырганнарны берәү дә туры юлга кертә алмас. Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаеклы илаһи зат юк, Ул — бер, тиңдәшсез һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм — Аның колы һәм расүле, дип шәһадәт китерәмен.

Мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең изге Мәккә шәһәреннән нурлы Мәдинә шәһәренә күчүеннән, ягъни һиҗрәт кылуыннан исәпләнә башланган һиҗри тәкъвим, календарь буенча яңа ел җитә. Мөхәррам ае – елның беренче ае һәм шулай ук Аллаһы Тәгалә аерым билгеләгән дүрт изге айның берсе:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ وَقَاتِلُوا الْمُشْرِكِينَ كَافَّةً كَمَا يُقَاتِلُونَكُمْ كَافَّةً ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ مَعَ الْمُتَّقِينَ

«**Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге** [катгый карарын белдергән] **язуында** [Ләүхелмәхфүздә] **— унике. Шуларның дүртесе — харам** [айлар]**. Бу —** [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең

харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән [галәйһиməссәлам] **калган] хак дин.** [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] **Боларда** [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] **үз-үзегезгә золым итмәгез. Алар сезгә каршы барчасы ничек сугышкан кебек, сездә** [куркуга төшеп качмыйча һәм бер-берегезгә ярдәм кулы сузып] **барчагыз мөшрикләр белән сугышыгыз һәм белегез, һичшиксез, Аллаһы —** [ярдәме Аның әмерләрен тотып, харамнардан сакланган] **тәкъвалык ияләре белән бергә».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Мөселманнарга шушы дүрт изге харам айларга игътибарлы булырга кирәк, чөнки Аллаһы Тәгалә бу айларны аерым билгеләде һәм гөнаһлар кылып, бу айларның изгелеген бозудан тыйды. Изге айларда кылынган гөнаһлар башка вакыттагыга караганда авыррак булып язылалар. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә аерып: «Ул дүрт айда үзегезгә золым кылмагыз», — ди.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе Ибне Габбас радыяллаһу ганһе изге айлар турында болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә унике айдан дүртесен сайлап, аларны изге итеп билгеләде. Һәм Ул шулай билгеләде ки, бу дүрт айда кылынган гөнаһлар авыррак, ә изге гамәлләрнең әҗерләре зуррак булып языла»[1].

Изге айлар барысы да Аллаһы каршында хөрмәтле булса да, мөхәррам ае алар арасында иң дәрәҗәлесе. Бу хакта Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе исемле сәхабә хәбәр итә: «Бервакыт мин: «Ий Аллаһының Илчесе, нинди колны азат итү иң хәерлесе? Төннең кайсы өлеше иң хәерлесе? Һәм кайсы ай иң хәерлесе?» — дип сораган идем. Ул минем бу сорауларыма болай дип җавап бирде: «Иң хәерле азат итү — иң кыйбатлы колны азат итү. Төннең иң хәерле өлеше ул — аның иң соңгы өлеше. Ә иң хәерле ай ул — Аллаһының ае, сез «мөхәррам» дип йөртә торган ай»[2].

---

1 Ибне Әби Хәтим «әт-Тәфсир» 1045, әт-Табари «әт-Тәфсир» 14/238.

2 Ән-Нәсаи «Сүнән әл-күбра», 4202.

Бөтен айлар да Аллаһы Тәгаләнеке булуына карамастан, Аллаһы Тәгалә мөхәррам аен Үзенеке дип аерып әйтә. Дин галимнәре әйтүенчә, бу мөхәррам аеның бөеклеге сәбәпле, һәм Рамазан аеннан соң иң хөрмәтле, бөек ай — мөхәррам ае. Ураза тотар өчен дә Рамазаннан соң иң яхшы вакыт булып мөхәррам ае тора. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе китергән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Рамазан аендагы уразадан соң иң хәерле ураза — Аллаһы Тәгаләнең ае булган мөхәррам аендагы ураза»[1].

Хәдистән күренгәнчә, мөхәррам ае өстәмә нәфел уразалар тоту өчен иң хәерле ай булып тора. Бу айның унынчы көне исә — уразада үткәрелә торган өстәмә фазыйләтле көн. Ул «Гашура көне» дип атала. Гашура көне элек-электән төрле диннәрдә хөрмәтле көн буларак билгеле булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күченеп килгәч, ул андагы яһүдиләрнең Гашура көнне ураза тотканнарын күреп, алардан моның сәбәбе турында сорый. Яһүдиләр болай дип җавап бирәләр: «Бу изге көн, бу көндә Аллаһы Бәнү Исраил халкын аларның дошманнарыннан, Фиргавеннән коткарды һәм Муса, Аллаһыга шөкер итү йөзеннән, бу көндә ураза тотты». Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Мин Мусага сездән якынрак», — дип җавап бирә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә бу көндә ураза тота торган була һәм сәхабәләренә дә ураза тотарга киңәш итә[2].

Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яһүдиләрдән аерылып торырга һәм уразаны бер Гашура көнендә генә тотмыйча, аннан алда да бер көн ураза тотарга киңәш иткән. Шулай итеп, мөхәррам аеның тугызынчы һәм унынчы көнен уразада үткәрү сөннәт булып санала. Ике көн тоту авыр тоелса яки мөмкинчелек булмаса, унынчы көнендә генә булса да ураза тотарга тырышырга кирәк, чөнки бу ураза зур фазыйләткә ия һәм аннан коры калу ул — зур нигъмәттән мәхрүм булу.

---

1 Мөслим, 1163.

2 Әл-Бохари, 3397.

Әбү Катәдә радыяллаһу ганһе китергән хәдистә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гашура көне уразасының фазыйләтен искә ала: «Рамазан аенда ураза тотып, аннан соң һәр айда өчәр көн өстәмә ураза тотучы кеше бертуктамый уразада булучыга тиң. Гарәфә көнендә тотылган ураза өчен Аллаһы Тәгалә алдагы елның һәм киләсе елның гөнаһларын кичерер, дип өметләнәм. Гашура көне уразасы өчен Аллаһы Тәгалә узган елның гөнаһларын кичерер, дип өметләнәм»[1].

Аллаһының киң рәхмәте, юмартлыгы, мәрхәмәте бит бу, мөхтәрәм җәмәгать. Бер көн ураза тоту белән безнең бер еллык гөнаһларыбыз кичерелә. Хәдистәге «кичерелер, дип өметләнәм» дигән сүзне дин галимнәре өметләнү Аллаһы Тәгаләгә бәйле булгач, бу, һичшиксез, үтәләчәк әйберне аңлата, диләр. Ягъни ураза тотсак, гөнаһлар һичшиксез кичереләчәк. Имам Бәйһакый әйтүенчә, әгәр Гашура көне уразасын тоткан вакытта кеше тәүбәләр белән гөнаһларыннан чистарынган булса, бу ураза аның Аллаһы Тәгалә каршында дәрәҗәсе артуга сәбәп булачак.

Гашура уразасының әҗере турында Әбү Катәдә радыяллаһу ганһе китергән хәдистә болай хәбәр ителә: «Бервакыт бер кеше Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән сораган иде: «Әй Аллаһының илчесе, Гашура көнендә ураза тотучы кеше турында нәрсә әйтерсең?» Ул: «Бу ураза бер ел дәвамында ураза тотуга тиң», — дип җавап бирде»[2].

Гашура көненең тарихыннан да без үзебез өчен файдалы гыйбрәт ала алабыз. Муса пәйгамбәр Бәнү Исраил халкы белән Фиргавен һәм аның гаскәреннән качкан вакытта алар диңгезгә килеп терәләләр. Шул вакытта Муса галәйһиссәлам кавемендәге кайбер кешеләр төшенкелеккә бирелеп: «Беттек, без инде тотылдык», — диләр. Муса пәйгамбәр исә аларга: «Юк, Раббым Аллаһы минем белән. Ул миңа чыгу юлын күрсәтәчәк», — дип җавап бирә. Шулвакыт Аллаһының әмере белән Муса диңгезгә суккач, диңгез ике

1 Мөслим, 2803

2 Ибне Хиббән, 3631.

якка аерылып, су төбендә коп-коры юл ачыла. Муса үз халкы белән диңгез аша чыгып котылалар, ә Фиргавен үз гаскәре белән алар артыннан куып диңгезгә кергәч, тау-тау булып торган су өемнәре тоташып, аларны һәлак итә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә бу вакыйганы тасвирлап болай дип әйтә:

فَأَتْبَعُوهُم مُّشْرِقِينَ ۞ فَلَمَّا تَرَاءَى الْجَمْعَانِ قَالَ أَصْحَابُ مُوسَىٰ إِنَّا
لَمُدْرَكُونَ ۞ قَالَ كَلَّا ۖ إِنَّ مَعِيَ رَبِّي سَيَهْدِينِ ۞ فَأَوْحَيْنَا إِلَىٰ مُوسَىٰ أَنِ
اضْرِب بِّعَصَاكَ الْبَحْرَ ۖ فَانفَلَقَ فَكَانَ كُلُّ فِرْقٍ كَالطَّوْدِ الْعَظِيمِ ۞ وَأَزْلَفْنَا ثَمَّ
الْآخَرِينَ ۞ وَأَنجَيْنَا مُوسَىٰ وَمَن مَّعَهُ أَجْمَعِينَ ۞ ثُمَّ أَغْرَقْنَا الْآخَرِينَ ۞
إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَةً ۖ وَمَا كَانَ أَكْثَرُهُم مُّؤْمِنِينَ ۞ وَإِنَّ رَبَّكَ لَهُوَ الْعَزِيزُ الرَّحِيمُ

«**Алар** [фиргавен һәм аның гаскәре] **кояш чыккан вакытта алар артыннан куып киттеләр. Ике төркем** [шактый якынлашып] **бер-берсен күргәч, Мусаның** [галәйһиссәлам] **аркадашлары:** «[Алдыбызда диңгез, артыбызда дошман] **Һичшиксез, без** [дошманнар тарафыннан] **куып җителгән кешеләрбез», — диде. Ул** [Аллаһының вәгъдәсенә ышанып]**: «Юк!** [Алар безне һич тота алмаслар! Аллаһы хакында начар уйламагыз!] **Һичшиксез, Раббым минем белән бергә, Ул** [котылуыбыз өчен] **миңа юл күрсәтәчәк!» — диде. Без Мусага** [галәйһиссәлам]**: «Таягың белән диңгезгә сук», — дип вәхи иттек.** [Ул бу әмерне үтәүгә] **Диңгез ярылды һәм һәрбер өлеш зур бер тау кебек булды. Башкаларны анда** [мөэминнәргә таба] **якынлаштырдык. Мусаны** [галәйһиссәлам] **һәм янында булганнарны барысын бергә коткардык. Шуннан** [алар диңгездән чыкканнан] **соң, башкаларны** [өсләренә диңгезне каплап] **суга батырдык. Һичшиксез, боларда** [Аллаһы Тәгаләнең өстен көчен күрсәткән] **бер билге** [һәм галәмәт] **бар. Әмма аларның күбесе**

**иман китерүчеләр түгел иде. Һичшиксез, синең Раббың — Бөек** [Җиңелмәс], **Рәхимле.**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:60–68

Чыгу юлы юк кебек тоелган шушы куркыныч хәлләрдән Аллаһы Тәгалә диңгезне ярып, чыгу юлы бирә. Дин галимнәре бу кыйссаның безгә бер дәресе шул диләр: «Синең каршыңда диңгез кадәрле, ырып-ерып чыга алмаслык авырлыклар, мәшәкатьләр булса да, әгәр Аллаһы Тәгалә синең белән булса, ул Муса пәйгамбәргә диңгездән юл ачкан кебек, синең диңгез кадәрле авырлыкларыңнан да чыгу юлын бирәчәк». Ләкин, Аллаһы Тәгаләнең безнең белән булуы шарт. Аның өчен безгә Аллаһының кушканнарын үтәп, изге гамәлләр кылып, Аны истә тотып яшәргә кирәк.

Бу вакыйгалардан ала торган тагын бер гыйбрәт — тәүбә итәргә, Аллаһыга буйсынырга ашыгырга кирәк. Диңгез төбендә су таулары астында бата башлагач, Фиргавен иман китерергә теләде, «мин мөселман булдым» дип кычкырды. Ләкин әҗәл вакыты килеп җиткәч, иманга килүдән файда юк.

وَجَاوَزْنَا بِبَنِي إِسْرَائِيلَ الْبَحْرَ فَأَتْبَعَهُمْ فِرْعَوْنُ وَجُنُودُهُ بَغْيًا وَعَدْوًا ۖ حَتَّىٰ إِذَا أَدْرَكَهُ الْغَرَقُ قَالَ آمَنتُ أَنَّهُ لَا إِلَٰهَ إِلَّا الَّذِي آمَنَتْ بِهِ بَنُو إِسْرَائِيلَ وَأَنَا مِنَ الْمُسْلِمِينَ ۞ آلْآنَ وَقَدْ عَصَيْتَ قَبْلُ وَكُنتَ مِنَ الْمُفْسِدِينَ ۞ فَالْيَوْمَ نُنَجِّيكَ بِبَدَنِكَ لِتَكُونَ لِمَنْ خَلْفَكَ آيَةً ۚ وَإِنَّ كَثِيرًا مِّنَ النَّاسِ عَنْ آيَاتِنَا لَغَافِلُونَ

**«Без Исраил улларын диңгез аша үткәрдек, Фиргавен һәм аның гаскәрләре исә золым һәм дошманлык белән аларны куа китте. Ул** [Фиргавен] **бата башлагач: «Һичшиксез, мин Исраил уллары ышанган Заттан башка һичбер илаһ булмаганына иман иттем. Мин дә —**

**мөселманнарданмын!» — диде.** [Шулвакыт аңа әйтелде] **«Хәзерме? Моңарчы** [Аллаһы Тәгаләгә] **каршы торган һәм** [кешеләрнең иманына комачау иткән] **бозыклык таратучылардан идең бит. Бүген Без синнән соң киләчәк кешеләр өчен бер аять** [һәм гыйбрәт] **булсын дип, сине** [җансыз бер хәлдә, ләкин бөтен] **бәдәнең белән коткарачакбыз».** [Менә бу кыйссада нинди зур гыйбрәтләр бар] **Әмма, һичшиксез, кешеләрнең күбесе Безнең аятьләребездән** [алар турында фикер йөртүдән] **гафилләр».**

«Юныс», 10:90–92

Күп кешеләр шулай ук изге гамәлләр кылырга ашыкмыйлар. «Намазга басарга, мәчеткә килергә әле иртәрәк, әле өлгерермен, мин әле әзер түгел», — дип яшиләр. Һаман кичектерә-кичектерә, әҗәл вакыты да килеп җитә. Шул вакытта кеше иман китерергә теләсә дә, иманы кабул булмый. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

هَلْ يَنظُرُونَ إِلَّا أَن تَأْتِيَهُمُ الْمَلَائِكَةُ أَوْ يَأْتِيَ رَبُّكَ أَوْ يَأْتِيَ بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ ۗ يَوْمَ يَأْتِي بَعْضُ آيَاتِ رَبِّكَ لَا يَنفَعُ نَفْسًا إِيمَانُهَا لَمْ تَكُنْ آمَنَتْ مِن قَبْلُ أَوْ كَسَبَتْ فِي إِيمَانِهَا خَيْرًا ۗ قُلِ انتَظِرُوا إِنَّا مُنتَظِرُونَ

**«Әллә алар үзләренә** [үлем һәм газап] **фәрештәләре килүен, яки Раббыңның** [Кыямәт һәм газап әмеренең] **килүен, яки** [Дәҗҗалның, Даббәтнең, кояшның көнбатыштан чыгуы кебек] **Раббыңның** [кыямәт] **аятьләреннән кайберләренең килүен көтәләрме? Раббыңның аятьләреннән кайберсе киләсе көнне, элегрәк ышанмаган яки иманында** [ихлас һәм тәүбә кебек] **бер хәер казанмаган җанга** [ул көндәге] **иманы файда бирмәячәк.** [Расүлем! Ул мөшрикләргә] **Әйт: «Сез көтегез, без дә** [боларның башыгызга килүен] **көтәчәкбез».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:158

Гашура көне белән бәйле дәресләрдән – изге гамәлләр кылып, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәргә кирәклеге булып тора. Муса пәйгамбәр Фиргавеннән котылгач, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп, Гашура көнендә ураза тота башлый. Ураза тоту, намаз уку, изге гамәлләр кылу — болар барсы да Аллаһыга шөкерле булуның күрсәткече. Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ни өчен аяклары шешкәнче, ярылганчы өстәмә намазлар укуы турында сорагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем шөкер итүче буласым килми мени?» — дип җавап бирә. Дин галимнәре әйтүенчә, Аллаһы безгә нигъмәтләрен арттырган саен, безнең изге гамәлләр кылуыбыз да артып барырга тиеш. Шулвакытта без ул нигъмәтләр өчен шөкер иткән булабыз. Шул рәвешле, шөкер итү «Аллаһыга шөкер», «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтү белән чикләнмичә, Аллаһы кушканнарны үтәүдә, изге гамәлләр кылуда чагылырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә безгә дә, изге гамәлләр кылып, Үзенә шөкерле булып яшәргә насыйп итсен. Гашура уразасы әҗерләрен алырга, мөхәррам аен изгелектә үткәреп, яңа башланган елны да хәерле гамәлләр белән үткәрергә насыйп булсын. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат Сәйфетдинов,*

*Теләче районы Сауш авылының «Хәлил» мәчете имам-хатыйбы*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# ДЕКАБРЬ-ФЕВРАЛЬ

## Чистайда Татарстан Аксакалларының 2023 елга хисап утырышы узды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 22 нче көнендә (6 декабрьдә) Татарстан мөфтиятенең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов җитәкчелегендә республика аксакаллары Чистай мөхтәсибәтендә күчмә киңәшмәдә катнашты. Чистай шәһәренең Ислам үзәгендә узган Еллык хисап утырышында Аксакаллар шурасының 2023 елга эш нәтиҗәләре чыгарылды. Алар — Татарстан башкаласында һәм мөхтәсибәтләрдә Хәтер көнен уздыру, Татарстанның дини-туристик маршрутларын үстерү һ. б.

## Мөфти Россиянең Динара советы утырышында дин тотучы тоткыннар өчен кысыр ризык ашау мөмкинлеген кертергә тәкъдим итте

Җөмәдәл-әүвәл аеның 23 нче көнендә (7 декабрьдә) Мәскәүдә Россия Динара советы Президиумы юбилей утырышы узды. Җыелыш Россия Динара советы оешуның 25 еллыгына багышлап, Мәскәү һәм бөтен Россия Патриархы Кирилл рәислегендә үтте. Утырыш барышында Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Патриархның игътибарын төзәтү учреждениеләренең дини оешмалар белән хезмәттәшлеге өлкәсендәге мәсьәләләрнең берсенә юнәлтте. Мөфти колонияләрдәге дин тотучылар өчен итсез кысыр ризыклы меню кертү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итте. Камил хәзрәтнең әлеге үтенече шуның белән бәйле ки: төрмәдә утырган дин тотучы мөселманнар өчен ризыкның хәләл булуы мөһим, ә кысыр меню, нинди дин тотуларына карамастан, барлык тоткыннарның да ихтыяҗын канәгатьләндерә алыр иде. Патриарх Кирилл Камил хәзрәтнең тәкъдимен уңай кабул итте һәм Россия Динара советы хакимиятләр белән берлектә бу мәсьәлә белән шөгыльләнәчәкләрен белдерде.

## Нәзарәтнең «Калям Шариф. Перевод смыслов» китабы сукырлар өчен Луи Брайль язуында басылып чыкты

Казанның «Ярдәм-Помощь» гомуммилләт хәйрия фондында «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасы сукырлар өчен Луи Брайль язуында дөнья күрде. Уникаль басма 10 томлык 100 комплект булып басылды һәм мөселманнар күпләп яшәгән төбәкләргә махсуслаштырылган китапханәләргә җибәрелде.

Коръәннең рус теленә мәгънәви тәрҗемәсе 2019 елда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Дагыстан Республикасы мөфтияте тарафыннан нәшер ителде. 2020 елда «Ярдәм-Помощь» гомуммилләт хәйрия фонды белгечләре Коръән тәфсиренең Брайль версиясен әзерләргә алынды: хәзер нокталы шрифтка җыелган 10 томдагы «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасын күрмәүчеләр дә укый ала.

## Нәзарәттә шәех Мәэмүн Әр-Рави катнашында Коръәннең кулъязма Мосхафын әзерләү комиссиясе утырышы узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 1 нче көнендә (14 декабрьдә) Татарстан мөфтияте бинасында Коръәннең кулъязма Мосхафын әзерләү комиссиясенең чираттагы утырышы үтте. Комиссияне Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкли.

Җыелышта катнашу өчен Дубайдан дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Изге Коръән Дубай халыкара премиясе (DIHQA) Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы, хафизлыкның иң югары дәрәҗәсенә ия булган, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел дәвамчысы шәех Мәэмүн Әр-Рави килде. Шәех утырышта чыгыш ясап: «Беренчедән, бу мосхафның уникальлеге — аның нәкъ менә шушы юнәлеш буенча 11 чыганакка таянып язылуында һәм башка бик күп мосхафлар һәм Коръән басмалары кулланылуында. Казан мосхафы ышанычлы чыганаклар белән чагыштырыла

һәм иң яхшысы Казан мүсхәфендә урын таба. ИншәАллаһ, бу мосхаф эталон булачак, ягъни аңа нигезләнеп башка мүсхәфләр язачаклар», — диде. Ул шулай ук Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә мондый проектның 8 ел дәвамында тормышка ашырылганлыгын әйтте. Хәзерге вакытта Казан кулъязма мүсхәфенең 320 бите (16 җүз) язылган, бу гомуми текстның яртысы дигән сүз.

## Нәзарәттә «Хашият Ибне Габидин» хезмәте буенча шәех Фарфурның лекцияләре узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 3–7 нче көннәрендә (16–20 декабрьдә) Татарстан мөфтиятендә шәех, шәригать фәннәре докторы, профессор Хусамеддин Мөхәммәд Салих Фарфур Әл-Кадирий Әл-Хәсәни булып китте. Ул Нәзарәттә «Радд-әл-мүхтәр галә дүрр-үл-мүхтәр» күптомлы хезмәтенә кереш буенча лекцияләр укыды. Нәзарәттәге лекцияләр тәмамланганнан соң, остаз Татарстан Мөфтие Камил хәзрәткә һәм дәресләрне тыңлаган башка укучыларга имам Ибне Габидин хезмәтләренә һәм Ибне Габидин үзенең остазыннан («Сабат Ибне Габидин») иҗазәт алган китапларга иҗазәтләр тапшырды. Бу исә дәресләрдә катнашкан хәзрәтләрнең иҗазәтләре имам Әбү Хәнифә белән Ибне Габидин аша үтүче өзлексез чылбыр белән тоташты дигән сүз. Иҗазәтләр тапшыру — «Радд-әл мүхтәр»нең кыскартылган версиясен әзерләгән өчен Фарфур остаз биргән югары бәя. Шәех, шәригать фәннәре докторы, профессор Хусамеддин Мөхәммәд Салих Фарфур әл-Кадирий әл-Хәсәни Татарстан Диния нәзарәте пленумы вакытында казыйларга һәм имам-мөхтәсибләргә дә дәрес бирде. Лекцияләр Коръән гыйлеме фәнендәге мөһим мәсьәләләрне өйрәнүгә багышланды.

## Нәзарәт Пленумында 2023 елга нәтиҗәләр ясалды һәм 2024 елга бурычлар куелды

Җөмәдәл-ахыр аеның 8 нче көнендә (21 декабрьдә) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы үтте. Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт

Сәмигуллин җитәкчелегендәге утырышта аның урынбасарлары, казыйлар, бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр, аларның ярдәмчеләре һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты. Пленумда Татарстан мөфтиятенең һәм аның карамагындагы оешмаларның 2023 елдагы эшчәнлегенә нәтиҗәләр ясалды һәм 2024 елга бурычлар билгеләнде.

Камил хәзрәт Нәзарәтнең 2024 елда берничә өстенлекле юнәлешкә игътибарны арттыру бурычын да куйды. Алар арасында ул Ислам финансларын үстерүне, Halal Life style концепциясен үстерүне, гаилә кыйммәтләрен ныгытуны, махсус хәрби операция зонасындагы солдатларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүне һәм мигрантлар белән эшләүне атады һәм барлык мөхтәсибләрне һәм нәзарәтнең оешма җитәкчеләрен шушы өлкәләргә игътибар биреп эшләргә чакырды. Моннан тыш, хәзрәт 2024 елны Нәзарәттә «Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы» дип игълан итәргә тәкъдим итте. Мөфтинең тәкъдимен Пленум бертавыштан хуплады.

## Питрәч мөхтәсибәтенең Беренче Май бистәсендә яңа мәчет ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көнендә (22 декабрьдә) Питрәч районының Беренче Май бистәсендә «Резеда» мәчете ачылды. Мәчеткә имам-хатыйб итеп Илшат хәзрәт Сәлахов билгеләнде. Бүгенге көндә Питрәч мөхтәсибәтендә 24 мәчет эшли.

## Әлмәт шәһәрендә яңа мәчет ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 15 нче көнендә (28 декабрьдә) Әлмәт шәһәрендә яңа мәчет үз ишекләрен ачып җибәрде. Әлмәтлеләрнең сөенечен бүлешеп, тантаналы ачылышта Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов катнашты. Бүгенге көндә Әлмәт мөхтәсибәтендә 43 мәчет эшли.

## «30/40» форумында бөтен Россиядән 70 мөселман катнашты

3–7 гыйнвар көннәрендә Болгарда Диния Нәзарәтенең 2020 елдан тормышка ашырыла башлаган «30/40» форумы узды. Анда Минск, Мәскәү, Самара, Санкт-Петербург, Чиләбе, Төмән, Оренбургтан, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарыннан 30–40 яшьлек 70 мөселман җыелды. Алар арасында гаиләле дин кардәшләребез дә бар иде.

«30/40» форумы — мөселман өммәтен берләштерү, белем алу һәм иманны ныгыту, хәләл ял итү һәм иҗат белән шөгыльләнү мәйданчыгы.

## Рамазан алдыннан Татарстан мәчетләрендә Коръән уку курслары оештырылды

Рамазан ае җитәргә 2 ай кала, раҗәб аеның 1 нче көнендә, 12 гыйнварда Казанның 9 мәчетендә һәм Питрәч мөхтәсибәтенең 1 мәчетендә халыкны Коръән укырга өйрәтү буенча 2 айлык укулар оештырылды. Дәресләр Татарстан мөфтияте һәм КИУның Госман ибне Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәгенең махсус программасы нигезендә узды. Мөгаллимнәр ике ай дәвамында гарәп әлифбасын һәм Коръән уку кагыйдәләрен өйрәтте.

## Казанда дин әһелләре олуг галим Шиһабетдин Мәрҗанине искә алды

Раҗәб аеның 5 нче көнендә (16 гыйнварда) татар-мөселман җәмәгатьчелеге бөек дин галиме, мәгърифәтче, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 206 ел тулу уңаеннан искә алу чарасына җыелды. Очрашу дин әһелләре, татар зыялылары, фән һәм җәмәгать эшлеклеләре, шәкертләр, журналистлар катнашында Казан шәһәре Яңа бистә зиратында рухи остазның кабере янында узды. Зиратта олуг галимне искә алу чарасында имамнар аятьләр укыды, аннары җыелган җәмәгать белән бергәләп дога кылды.

## Татарстан мөхтәсибәтләре кар күп яву сәбәпле олы юлда калган юлчыларга ярдәм итте

Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре кар күп яву аркасында килгән авырлыкларны хәл итү эшенә кушылды. Һава торышы начар булганлыктан юл читендә туктап калырга мәҗбүр булган йөк машиналарын йөртүчеләр кайнар аш белән тәэмин ителде: Түбән Кама һәм Бөгелмә мөхтәсибәте вәкилләре трассада калган юлчыларга ярдәм итәргә чыкты. Түбән Кама районында кайнар ашны 250 гә якын йөк машинасы йөртүчесе алды. Мәхәлләләр шулай ук су һәм озак саклана торган азык-төлек белән ярдәм күрсәтте. Ә Бөгелмә мөселманнары Карабаш бистәсе янында үтүче Р-239 трассасында район мөхтәсибәте белән берлектә 25 фура йөртүчегә кайнар ризык: бәрәңге шулпасы, пылау, салат, коймак, ипи, су таратты.

## Нәзарәттә мөселман яшьләре форумының кышкы мәктәбе эшләде

Гыйнвар аенда Нәзарәттә XVII Мөселман яшьләре форумы эшләде. Кышкы мәктәпкә барлыгы 140 егет һәм кыз гариза бирде. Узган елдагы кебек үк, ул егетләр һәм кызлар өчен аерым оештырылды. Мөселман яшьләренең Россиякүләм җыенында Мәскәү, Казан, Екатеринбург, Чаллы, Арча шәһәрләреннән, Оренбург, Свердловск өлкәләре, Чувашия Республикасы һәм Татарстанның Әлмәт, Лаеш, Мамадыш районнарыннан 18–30 яшьлек 50 егет, Татарстанның Казан, Чаллы, Чистай, Нократ Аланы; Россиянең Мәскәү, Уфа, Дондагы Ростов, Сарытау, Екатеринбург, Ульяновск, Омск, Чабаксар, Сызрань шәһәрләреннән 75 кыз катнашты.

Әлеге форум 2015 елдан Татарстан мөфтияте тарафыннан мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән үткәрелә.

## Нәзарәт яңа финанс продуктын — Ак Барс Банкының ислам факторингын хуплады

Раҗәб аеның 15 нче көнендә (26 гыйнварда) Нәзарәттә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Ак Барс Банкының цифрлы факторинг идарәсе башлыгы Алексей Дробот белән эшлекле очрашу үткәрде. Әлеге киңәшмәдә шулай ук Татарстан мөфтиятенең Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе, шәригать фәннәре докторы Рөстәм хәзрәт Нургалиев катнашты. Очрашу яңа финанс продукты — Ак Барс Банкының ислам факторингын гамәлгә кертү мәсьәләләренә багышланды.

Яңа финанс продукты Россия ислам институты каршындагы Россия Ислам икътисады һәм финанслары үзәгендә эшләнде һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы тарафыннан югары бәяләнде. Нәзарәт тәкъдим ителгән документлар җыелмасы белән танышып һәм аларны өйрәнеп, әлеге продуктны ислам хокукы кануннары нигезендә рөхсәт ителгән дип тапты. Ислам финанс продуктын гамәлгә ашыручы шәригать контролеры итеп шәригать фәннәре докторы Рөстәм хәзрәт Нургалиев билгеләнде. Камил хәзрәт Сәмигуллин Алексей Дроботка Татарстан мөфтияте Голәмәләр шурасының бу финанс продуктның рөхсәт ителүе турындагы карарын тапшырды.

Бүгенге көндә Россия ислам институты һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте алып барган тикшерү эшләре нәтиҗәсендә мөселманнарның төп ихтыяҗларына җавап бирерлек 11 ислам банк продукты бар.

## Казанда «Вәгазь» телевизион ачык конкурсында җиңүчеләрне бүләкләделәр

Раҗәб аеның 19 нчы көнендә (30 гыйнварда) Казанда «Вәгазь» телевизион ачык конкурсында җиңүчеләрне бүләкләделәр. «Вәгазь» телевизион ачык конкурсын Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясе Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә 2023 елның 1 мартыннан 1 октябренә кадәр

игълан иткән иде. Бәйгенең төп максаты вәгазь жанрын популярлаштыру һәм татар телендә иң оста вәгазьчеләрне ачыклау; төрле темага вәгазьләр иҗат итүгә этәргеч бирү; вәгазьләрне халыкка үтемле итеп сөйләү үрнәген булдыру; оста вәгазьчеләрне барлау һәм халыкка танытудан гыйбарәт.

«Вәгазь» телевизион ачык конкурсына Татарстанның төрле район һәм шәһәрләреннән барлыгы 200 дән артык гариза килде. Катнашучылар арасында халыкка исемнәре мәгълүм булган хәзрәтләр дә, республика мәдрәсәләре шәкертләре дә булды. Конкурска килгән вәгазьләр арасыннан төрле темага язылган 50 вәгазь сайлап алынып, атна саен Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясенең «Яңалыклар» тапшыруының җомга чыгарылышыннан соң тамашачы игътибарына тәкъдим ителде.

## Нәзарәт махсус хәрби операция зонасына үзе шефлык иткән хәрби částька 5 нче гуманитар йөкне илтте

Диния нәзарәте делегациясе Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатларга махсус хәрби операция зонасына рухи һәм гуманитар ярдәм күрсәтү өчен чираттагы сәфәр кылды. Сәфәр вакытында мөфтият Луганск Халык Республикасы юнәлешендә урнашкан хәрби подразделениегә 5 нче тапкыр гуманитар йөк илтеп кайтты. Хәрби частьнең 90%-ы Татарстан солдатларыннан тора, алар арасында намаз укучы мөселманнар да бар.

Моннан тыш, сәфәр барышында Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгыш төбәге казые Марат хәзрәт Мәрданшин Луганск, Северодонецк һәм Татарстан шефлык итүче Лисичанск шәһәрләрендә булды. Делегация шәһәрләрдәге объектлар һәм торак йортларның торышы, Лисичанскны торгызу барышы белән танышты, шулай ук Луганскидагы госпитальгә барды. Луганскиның Җәмигъ мәчетендә хәзрәтләр Луганск халык республикасы мөфтие Мөхәммәт Гамбәров һәм имамнар белән очрашты һәм

ЛНР мөселманнары Диния нәзарәтенә «Хозур» нәшриятында басылган дини әдәбиятны тапшырды. Монда алар шулай ук хәрби подразделение солдатлары һәм җирле мөселманнар белән очрашты. Шуннан соң Мөфти Камил хәзрәт җомга намазын үткәрде.

## Казанда Халыкара хиҗаб көненә багышланган чара узды

Раҗәб аеның 27 нче көнендә (7 февральдә) Казанда Халыкара хиҗаб көненә багышланган чара узды. Аны ТР мөселманнары Диния нәзәрәте һәм Татарстан мөслимәләре берлеге уздырды. Әлеге чарада катнашучыларны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, адвокат һәм юрист Руслан Нагиев, Татарстан Мөслимәләре берлеге җитәкчесе Наилә Җиһаншина, Төркия кунаклары һ. б. сәламләде. Камил хәзрәт чараны изге Коръәннән аятьләр укып башлап җибәреп, хиҗаб киюнең Коръән һәм Сөннәттә килгән хөкемнәре белән таныштырды, хиҗаб киюнең Аллаһының әмере, ягъни фарыз гамәл булуын ассызыклады. Ул шулай ук хиҗабның фарызлыгы турында аңлату эшләре алып барырга өндәде.

## Нәзарәт яңартылган «Казан басмасы»н дини һәм татар милли иҗтимагый оешмаларына тарата

ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә мөселманнар күпләп яшәгән Россия төбәкләрендә бушлай тарату өчен яңартылган «Казан басмасы»ның махсус тиражы басылып чыкты. Мосхафлар Катарның вакф һәм Ислам эшләре буенча министрлык каршындагы вакфлар эшләре буенча идарәнең финанс ярдәме белән бастырылды. Нәзарәт мосхафларны «Казан басмасы»ның 220 еллыгы уңаеннан «Хозур» нәшриятында бастырды.

30 мең данә Коръән дин кардәшләргә дини һәм татар милли иҗтимагый оешмалары аша таратыла. Мосхафлар татар дин әһелләре форумында тарату өчен — Бөтендөнья татар конгрессына; Россиянең Азия өлеше мөселманнары

Диния нәзарәтенә, Россия Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә, шулай ук мәчетләргә, мөхтәсибләргә тапшырылды.

## Нәзарәт, «Хәләл» стандарты буенча Комитет һәм Роскачество башлыклары килешү имзалады

Диния нәзарәте, Россия сыйфат системасы (Роскачество) һәм Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча Комитеты Россиядә хәләл индустрияне үстерү буенча бердәм хезмәттәшлек алып бару хакында килеште. Республика территориясендә Роскачество каршындагы Хәләл буенча компетенцияләр федераль үзәгенең территориаль вәкиллеге ачыла, ул Татарстан мөфтияте Комитеты белән тыгыз хезмәттәшлектә эшлиячәк.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия сыйфат системасы җитәкчесе Максим Протасов һәм Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты буенча Комитет рәисе Габбас хәзрәт Шляпошников Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, республика закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары вәкилләре катнашында тиешле килешүгә кул куйды.

Килешү илебезнең хәләл индустриясен системалаштырырга, хәләл товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр стандартлары буенча сертификацияләүгә, хәләл индустриясе белән идарә итү, җитештерү, хәләл продукциянең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфат менеджменты системаларын кертү процессларының нәтиҗәлелеген күтәрергә, шулай ук кадрлар һәм белем бирү программаларын әзерләүне җайга салырга мөмкинлек бирәчәк. Моннан тыш, уртак эшчәнлек Россия Федерациясе территориясендә һәм халыкара дәрәҗәдә хәләл өлкәне таныту һәм популярлаштыруны көчәйтәчәк.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең хәләл инстуриияне үстерү өлкәсендә зур һәм алдынгы тәҗрибәсен исәпкә алып, Камил хәзрәт Сәмигуллин Хәләл буенча компетенцияләр үзәгенең Күзәтчелек советы соста-

вына керә. Роскачество карамагындагы Хәләл буенча компетенцияләр Үзәге намаз укучы мөселманнардан тора һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән мәгълүмат алмашачак, уртак күргәзмәләр, форумнар һәм семинарлар үткәрәчәк.

## Рамазан ае алдыннан Татарстанда чираттагы республикакүләм «Татар азаны» бәйгесе игълан ителде

Татарстанда Рамазан алдыннан татар мәкаме белән азан әйтү бәйгесе башланды. Анда 5 яшьтән өлкәнрәк һәм балигълыкка ирешмәгән малайлар катнаша ала. Конкурсның төп оештыручысы — «Рухи моң» иҗат берләшмәсе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Ислам кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәсе. Бәйге милли мәкам һәм традицион мелодика калыпларын кайтару; татар мәкаме белән азан әйтү культурасын булдыру; татар теленең кулланылыш даирәсен арттыру; Татарстан мәчетләреннән яңгыраучы азаннарның сыйфатын яхшырту һәм милли мәкамле азан традицияләрен торгызу максатын куя.

## Нәзарәт тарафыннан яңа ислам финанс продуктлары — Ак Барс Банкының хисап-касса хезмәте һәм корпоратив картасы хупланды

Шәгъбан аеның 10 нчы көнендә (20 февральдә), «Кол Шәриф» мәчетендә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән Ак Барс Банкы идарәсе рәисе урынбасары Ольга Ясонованың эшлекле очрашуы узды. Киңәшмәдә шулай ук Татарстан мөфтиятенең Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе, шәригать фәннәре докторы Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Ак Барс Банкының транзакцион

бизнес идарәсе башлыгы Илдар Абдуллин, Ак Барс Банкының ислам банкингы юнәлеше җитәкчесе Марат Садриев катнашты.

Очрашу яңа ислам финанс продуктларын — хисап-касса хезмәте һәм Татарстан мөфтиятендә хупланган Ак Барс Банкының хәләл стандартлары буенча корпоратив картасы хакында фикер алышуга багышланды. Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Ак Барс Банкы идарәсе рәисе урынбасары Ольга Ясоновага Татарстан мөфтияте Голәмәләр шурасының әлеге финанс продуктының рөхсәт ителүе турындагы карарын тапшырды.

Нәзарәт тәкъдим ителгән документлар җыелмасы белән танышып һәм аларны өйрәнеп, әлеге продуктларны ислам хокукы кануннары нигезендә рөхсәт ителгән дип тапты. Продуктларны ныклап өйрәнгәннән соң, алар шәригать принципларына туры килә, дип табылды. Картага хезмәт күрсәтү дә бушлай алып барыла. Ислам продуктлары акчаны махсус счётта уңайлы итеп сакларга, хәйрия ярдәме күрсәтергә, кибетләрдә, интернетта ислам принципларына ярашлы рәвештә сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләргә мөмкинлек бирә. Шулай итеп, клиентлар шәригать тарафыннан тыелган операцияләрне финанслаудан читтә кала.

## Лаешта Татарстан Рәисе һәм Мөфти катнашында «Ак Мәчет «Зәйнәб» Җәмигъ мәчете ачылды

26 февральдә, Рамазан-шәриф ае башланырга төп-төгәл ике атна кала, Лаеш шәһәре үзәгендә «Ак Мәчет «Зәйнәб» Җәмигъ мәчете үз ишекләрен ачты. Дин кардәшләребезнең олуг сөенечен бүлешергә һәм яңа мәчет белән танышырга Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, республика һәм муниципаль хакимият органнары, төрле министрлык һәм ведомство вәкилләре, күпләгән җитәкчеләр, депутатлар, дин әһелләре, мәхәллә халкы җыелды.